# Түгәрәк уен

ТАТАР ХАЛЫК ИҖАТЫН ЯКТЫРТУЧЫ МӘГЪЛҮМАТИ-ПОПУЛЯР АЛЬМАНАХ 2/ 2022

*Миллилек – чын сәнгатьнең алыштыргысыз өлеше. Әлеге текстиль курчакларга да милли колорит хас. Алар милли киемле сувенирлар гына түгел, холкы һәм яшәү рәвеше күрсәтелгән шәхесләргә тиң*







*«Сабантуй – чын-мәгънәсендә милли рух җәүһәре, татар халкының үзенчәлекле мәдәниятенең бетмәс-төкәнмәс чишмәсе, аның рухи торышы, һәм талантларны ачу өчен бик яхшы мөмкинлек, җитезлектә, тапкырлыкта көч сынашу...»*

*Татарстан Республикасының*
*беренче Президенты*
*Минтимер ШӘЙМИЕВ*





# Түгәрәк уен

№ 2 / 2022

*Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул,*
*моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул.*
*Г. Тукай*


16+ Татар халык иҗатын яктыртучы мәгълүмати-популяр альманах

Гамәлгә куючылар:
Татарстан Республикасы
Мәдәният министрлыгы каршындагы
Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге

Редколлегия:
Ирада Әюпова
Марсель Бакиров
Разил Вәлиев
Тәлгат Галиуллин
Дания Заһидуллина
Марс Тукаев
Фәрит Юсупов

Директор: Алсу Равил кызы Мифтахова
Баш мөхәррир: Рәзинә Әхтәм кызы Исмәгыйлева

Альманахның иҗат төркеме:
Гөлназ Латыйпова
Рәмзия Гайфетдинова
Илнара Гәрәева

Дизайнер һәм биткә салучы:
Диләрә Нәүрузова

Альманах 2020 елның 13 ноябрендә элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр даирәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәт идарәсендә (Роскомнадзор) теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-79590.
Журнал өч айга бер чыга. Бәясе ирекле.

Кәгазь форматы 60×90 ⅛. Күләме 8 басма табак.
Басарга кул куелды: 08.06.2022
Чыгу көне: 15.06.2022
Заказ: 065412
Тираж: 1000 экз.

Редакция һәм нәшер итүче:
420021, Казан, Тукай ур., 74 а.
Хатлар язар өчен адрес:
420015, Казан, Пушкин ур., 66/33
Телефон: 293-27-99.
E-mail: tugarakuen@mail.ru

«Визард» ҖЧҖндә бастырылды.
Казан, Җиңү проспекты, 78



Кулъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.
Күчереп басканда, «Түгәрәк уен» альманахына сылтама ясау мәҗбүри.



**Тышлыкта:** «Күршеләр-ахирәтләр», 2004 ел.
Рәссам Наилә Галәвиева



© «Түгәрәк уен», 2022



**ТАТАР ДӨНЬЯСЫНЫҢ ТРАДИЦИОН МӘДӘНИЯТЕ ЯҢАЛЫКЛАРЫ**

4 **«Тылдагы батырлык» марафоны**

7 **«Милли костюм театры» традицияләрне саклау мәсьәләләрен күтәрә**

10 **«Илаһи моң» төбәкара бәйгесе**

**ХАЛКЫМНЫҢ ОСТА КУЛЛАРЫ**

14 Х. Баһаветдинова
**Казан арты татар авылларында чыпта сугу тарихыннан**

**ХАЛКЫБЫЗНЫҢ КҮРКӘМ БӘЙРӘМНӘРЕ**

18 Р. Мәһдиева
**Гасырлардан килгән көрәш**

24 З. Мөхәммәтшина
**Апас Сабан туена рәхим итегез!**

29 Р. Хөсәенова
**Самавыр бәйрәме**

**ҺӨНӘРЛЕ ҮЛМӘС...**

35 Е. Шемелова
**Буыннар хәтерен саклагыз!**

**БЕЗГӘ ЯЗАЛАР**

40 Г. Хөснетдинова, Ә. Гыйльманова
**Бәһиҗә апа калфагы**

42 Ч. Нурмөхәмәтова
**Кулымдагы курчагымның исемнәре Фатыйма**

**ӘДӘБИ МИРАС**

44 Л. Мөхәммәтҗанова
**Тыпыр-тыпыр биегәндә...**
*(Татар халык иҗатында уен һәм бию такмаклары)*
















**МӘДӘНИЯТ**

48 Р. Мөхәммәтова
**Мәсгудә Шәмсетдинова: «Йолдыз Исәнбәт мине даhи ялкау дип сүгә иде»**

**БЕЗНЕҢ КИТАПХАНӘ**

51 А. Галиева
**Мифология – халык иҗатының иң борынгы катламы**

52 **Хайван хуҗалары абзар иясе бар...**

**БЕЗ, БЕЗ, БЕЗ ИДЕК...**

54 Р. Гайфетдинова
**«Карга боткасы» йоласы**

57 **Авылда** *(Җыр)*

58 Р. Сәйфетдинова
**«Түбәтәй» уены**

**ӨЙ КҮРКЕ – АШ**

60 **Гөбәдия**

**ЯЛ СӘГАТЬЛӘРЕНДӘ**

64 **Шахворд**

1941 Сурский Казанский рубеж 1942




# «Тылдагы батырлык» марафоны

■ Татарстан һәм Чувашия республикаларында Бөек Ватан сугышы елларында Казан каймасы һәм Сура оборона чиген төзүчеләрнең хезмәт батырлыгына багышланган «Тылдагы батырлык» төбәкара патриотик марафоны узды. Татарстанда марафон чаралары Олы Кайбыч авылында, Апас бистәсендә, Тәтеш һәм Буа шәһәрләрендә үткәрелде. Марафон дәвамында үткән истәлекле чаралар Казан каймасы һәм Сура оборона чиге төзелеше тәмамлануга 80 еллыкка багышланган иде.

Казан каймасы һәм Сура оборона чиген төзүче тыл хезмәтчәннәренең батырлыгы – Ватанга хезмәт итүнең, хәрби-патриотик һәм рухи-әхлакый каһарманлыкның лаеклы үрнәге. Халкыбызның бу фидакарьлеге Бөек Ватан сугышы елъязмасында аерым урын алып тора, ике республика халкының кече ватанга мәхәббәте булып гәүдәләнә. «Тылдагы батырлык» төбәкара патриотик марафоны яшь буынга патриотик тәрбия бирү, ориентирлар формалаштыру чарасы: алар әби-бабаларының Бөек Җиңүгә фронтта гына түгел, тылда да зур өлеш кертүе белән горурлана ала.

Марафон быелның 11 маенда ике зур чара белән тәгәлләнде. Болар:

– Казан (Идел буе) федераль университетында «Тылда хезмәт батырлыгы: Казан каймасы һәм Сура оборона чиге төзелеше» регионара фәнни-гамәли конференция;










– Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе залында ике республиканың иҗат коллективлары һәм артистлары катнашындагы концерт. Әлеге тантаналы кичәдә Казан каймасы һәм Сура оборона чиге төзелеше ветераннарына медальләр тапшырылды.

Конференциядә тарихчылар, туган якны өйрәнүчеләр һәм укытучылар ясаган чыгышлар тиздән җыентык булып басылып чыгачак.




Марафонны оештыручылар: Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Чувашия Республикасының мәдәният, милләтләр буенча эшләр һәм архив эше министрлыгы, Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге, Чувашия Республикасының Дәүләт тарихи архивы, Казан (Идел буе) федераль университеты, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге Тарих институты.





# «Милли костюм театры» традицияләрне саклау мәсьәләләрен күтәрә

■ Казанда Чечен мәдәнияте көннәре барганда ике республиканың мәдәният министрлары – Ирада Әюпова һәм Айшат Кадыйрова «Казан Кремле» музей-тыюлыгында «Милли костюм театры»н тамаша кылды.

Биредә коллекцияләре тәкъдим ителгән дизайнерлар, этнографлар, костюмнар тарихы буенча белгечләр, профессиональ һәм югары уку йортлары вәкилләре һәм республиканың яшь дизайнерлары катнашында түгәрәк өстәл узды. Катнашучылар яшь дизайнерларны укыту һәм аларга брендларын үстерү өчен оптималь шартлар тудыру, киемнәрдә милли традицияләрне саклау һәм популярлаштыру мәсьәләләре турында фикер алыштылар.






















ФУАД ВАЛЕЕВ
ТАТАРСКОЕ НАРОДНОЕ ДЕКОРАТИВНОЕ ИСКУССТВО
ОТ ТАМГИ ДО АВАНГАРДА

# Төбәкара бәйге

Илаһи моң



Республикабызда алтынчы ел рәттән «Илаһи моң» татар халкының рухи мирасы үрнәкләрен һәм халык авыз иҗаты әсәрләрен башкаручылар бәйгесе үткәрелә. Быел бу бәйгенең финалына чыгучыларга Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам кабул ителүнең 1100 еллыгы уңаеннан Болгар дәүләт тари-хи-архитектура музей-тыюлыгында үткәрелгән зур бәйрәмдә катнашу насыйп булды.

Әлеге бәйгедә Татарстан районнарыннан һәм Россия регионнары – Иркутск, Киров,





Ульяновск өлкәләреннән, Мәскәүдән һәм Чувашиядән 130дан артык кеше катнашты. Алар арасында мәктәп укучыларыннан башлап, урта һәм югары уку йортлары студентлары, төрле яшьтәге профессиональ һәм һәвәскәр башкаручылар бар иде. Халык авыз иҗаты булган мөнәҗәтләр, бәетләр, эпос-дастаннар, догалар, зикерләр белән бергә «Кыйссаи Йосыф», «Бәдавам», «Кисекбаш» кебек әдәби мирас үрнәкләре дә башкарылды, традицион татар мәкаме белән Коръән дә укылды.

«Халык арасында мөселман традицияләре буенча көйләүгә игътибар артуы сизелә, бу быел – Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам кабул ителүнең 1100 еллыгы елында аеруча игътибарга лаек», – ди Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге директоры Алсу Мифтахова.

Бәйгенең сайлап алу этабы 5-31 март көннәрендә узды. 14 апрельдә экспертлар, жюри әгъзалары, педагоглар һәм иҗат коллективлары җитәкчеләре катнашында «Татар рухи мәдәниятендә дин һәм музыка» дип аталган түгәрәк өстәл оештырылды.















20 майда бәйге кысаларында катнашучылар өчен Мәрҗани мәчетендә «Ислам мәдәниятендә көйләп уку серләре» дип аталган семинар үткәрелде. Лауреатларга грамоталар, дипломнар һәм сертификатлар да биредә тапшырылды.

«Илаһи моң» төбәкара бәйгесен оештыручылар: Россия ислам институты, Бөтендөнья татар конгрессы, Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге, Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте.





Яңалыклардагы фоторәсемнәр Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге архивыннан

*Халидә БАҺАВЕТДИНОВА,*
*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты фәнни хезмәткәре*

# КАЗАН АРТЫ ТАТАР АВЫЛЛАРЫНДА *чыпта сугу тарихыннан*

***XIX гасыр урталарында крестьяннар игенчелек һәм, гомумән, авыл хуҗалыгы белән генә гаилә туендыра алмаганга төрле кәсеп белән шөгыльләнгәннәр. Казан артында иң киң таралган һөнәрләрнең берсе чыпта җитештерү булган.***

Товар ташу. В.Л. Лаптев фотосы. 1927 ел.
m.realnoevremya.ru/articles/156144-aleksey-klochkov-o-mochalnoy-ploschadi-kazani





Чыпта – мунчала тасмалардан сугылган тупас тукыма. Чыпта сугу өчен юкә агачы кайрысын суга салып торганнар һәм мунчаласын аерганнар.

Казан губернасында бу кәсеп XIX гасырның беренче яртысында үсеш алган. Казан өязе чыпта җитештерү буенча гасыр уртасына Россия империясендә алдынгы урынны биләгән. Продукциянең төп өлеше Казанда сатылган. «Казанские губернские ведомости» газетасында чыккан мәкалә авторының бәяләмәсе буенча, 1840 еллар уртасында февральдән мартка кадәр, шәһәр сәүдә мәйданчыкларында 216 меңләп чыпта (3600 олау), шулай ук, гомуми суммасы 1 миллионга җиткән зур микъдарда чыпта җәймәләр белән кап сатылган. Бу вакытта Казанда чыпта һәм канат-бау кабул итү һәм сату буенча махсуслашкан 18 лавка (кибет), 4 канат-бау җитештерү заводы, шулай ук сәүдәгәр Софроновның елына 5 мең потка кадәр мунчала эшкәртү фабрикасы булган.

Җирле осталарның товары Казан губернасында гына түгел, башка төбәкләрдә дә югары бәяләнгән, аларга ихтыяҗ зур булган. Аеруча Чар (Царевококшай) өязе татарлары җитештергән чыпта яхшылардан саналган. Ветлуга һәм Варнава һөнәрчеләренекенә караганда (100 данәсе 27

**Чыпта сугу станогы.**
**Казан губернасы. 1886 ел.**
**m.realnoevremya.ru/articles/156144-aleksey-klochkov-o-mochalnoy-ploschadi-kazani**



сумнан 30 сумга кадәр) Казан өязендә җитештерелгән чыпта күпкә кыйммәт (100 данәсе 90 сум) йөргән.

Җирле халык белән күрше марилар үзара аралашып яшәгән. 1830 елларда Атамыш (Әтнә районына карый. Руслар нигез салган һәм яшәгән. Бүгенге көндә юкка чыккан) авылы кешесе Чар өязенең Арбан волостенда эшләп көн күргәндә, чыпта сугу һөнәренә өйрәнә. Авылына кайткач, юкә мунчаласыннан чыпта ясап сата башлый һәм шул кәсебе нәтиҗәсендә бик тиз баеп китә. Аннан күреп, Күлле Киме волостеның 11 авылында халык чыпта җитештерү белән шөгыльләнә башлый. Чар өязенә кергән татар авыллары чыпта ясау һөнәренә күрше-тирә мари авылларыннан өйрәнгән, дигән фикер бар.

Беренче карашка гади генә булып күренсә дә, чыпта үрү – шактый зур көч таләп итә торган хезмәт була. Җитештерү гаять авыр, кайчак санитария кагыйдәләрен үтәп булмаган шартларда барган. Эшләү өчен аерым биналар булмаган, кешеләр яши торган ызбада башкарылган. Андый шартларда пөхтәлек-чисталык саклавы авыр, әлбәттә, өстәвенә, крестьяннар кышкы суыкларда мал-туарын да өйгә керткән, шуңа да йортта дымлы һава һәм тынчу ис торган. Чыпта сукканда, моңа мунчала тузаны да өстәлгән. Мондый шартлар кеше сәламәтлегенә зыян салган.

Гадәттә бу эшне, урып-җыю эшләре тәмамлангач, көз ахырыннан язга кадәр башкарганнар. Чыпта ясаучылар тәүлегенә 14әр сәгать эшләгән – төнге сәгать 2дә башланган эш, кыска тәнәфесләр ясап, кичке 8дә тәмамланган. Гадәттә, бөтен гаилә белән эшләгәннәр, балалар да читтә калмаган: кечерәк малайлар мунчала әзерләсә, үсмер яшьтәгеләре «энәче» вазифасын башкарган.

1870 еллар уртасында бу кәсеп Күлле Киме волостеның татар авылларында зур үсеш ала: Ары авылында чыпта җитештерүдә – 10, Түбән Көектә – 15, Яңа Шимбердә – 15, Өләдә – 20 кеше эшли. 1880 еллар уртасына Күлле Киме волостенда чыпта кәсебе белән еллык keremнәре 10111 сум тәшкил иткән 425 гаилә (1364 эшче) шөгыльләнгәне билгеле.

XIX гасырның икенче яртысында, үз ызбасында чыпта сугу белән шөгыльләнгән аерым хуҗалыклар белән беррәттән, мануфактура җитештерүче артельләр дә барлыкка килгән. Мондый артельләрне булдыклы осталар төзегән, яисә чыпта сатучы сәүдәгәрләр оештырган. Махсус станоклар һәм эш кораллары белән җиһазланган, хезмәт бүленеше булган артельщикларның кереме аерым һөнәрчеләрнекенә караганда шактый югары булган. Артель, кагыйдә буларак, 3-4 кешедән торган. Араларында иң тәҗрибәле кеше мунчала сортлау, чыпта «җебен озату» һәм «аркау җебе» өчен материал сайлау белән шөгыльләнгән. Ике эшче чыпта суккан: берсе мунчалаларны буй-буй итеп салып, агач калак белән төртеп торган, икенче эшче станокның каршы ягыннан аркау җебе өчен әзерләнгән мунчалаларны агач энәгә керткән. Эше җайга салынган артель 12 көн эчендә сигез потлы йөзләп чыпта җитештергән.

Чыпта ясау кәсебе аеруча 1880 еллар уртасында арткан. Бу чорда Яңа Шимбердә 101 кеше чыпта ясау һәм чыпта җәймә үрү белән шөгыльләнгән. Шул рәвешле, авылның хезмәткә яраклы күпчелек кешесе чыпта ясау эшенә җәлеп ителгән.

Чар өязенең *(Казан губернасына караган. ТАССР оештырылганнан соң аның күп өлеше Мари-Элга керә. –* **Авт.***)* татар авылларында мунчала җитештерүнең киң таралуы Казан губернасының икмәк сәүдәсендәге роленә бәйле булган. Казанда һәм губернаның башка эре сәүдә үзәкләрендә Идел буеннан китерелгән икмәк күпләп сатылган һәм сатып алынган. Казан губернасында эре елга портларының булуы да мөһим роль уйнаган: бөртекле ашлык су юлы белән империянең башка регионнарына озатылган. Нәкъ менә икмәк белән сәүдә итүчеләр чыптадан ясалган капларны күпләп алучылар булган да инде.

1895 елда Казан земствосы әгъзалары раславынча: «Чыпта һәм кап сугу маклер-подрядчиклар – хәлле крестьяннар һәм шәһәр сәүдәгәрләре кулында; крестьяннар алардан чимал сыйфатында мунчала ала да, аннан чыпта ясап яки капчык тегеп, шул ук подрядчиклар аша күпләп сатып алучыларга тапшыралар. Сәүдәгәрләр сатып алу бәясен бик түбән кую сәбәпле, крестьяннарга авыр хезмәт өчен аз түләнә. 1880 еллар уртасында сигез потлы йөз чыпта өчен, чимал бәясен исәпкә алмаганда, заказ бирүчеләр эшчеләргә 2 сум 50 тиен түли. Казанда исә шул сандагы чыпта 12 сум тора. Мунчала бәясен исәпләмәгәндә, алыпсатар 6 сум 20 тиен чиста керем ала».

Нәкъ менә төп чимал – мунчала бәясе үсү белән бергә базарның монополияләшүе, юкә урманнарын күпләп кисү нәтиҗәсендә 1890 елларда мунчала эшкәртү кәсебенең әһәмияте бик нык кими. 1880 еллар ахыры – 1890 еллар башын-



**Ашлык төяү.
В.Л. Лаптев фотосы. 1927 ел.
m.realnoevremya.ru/articles/
156144-aleksey-klochkov-
o-mochalnoy-ploschadi-kazani**

дагы уңдырышсыз еллар чыпта сугу эшенә дә тәэсир итә: икмәк сәүдәсе кими һәм шул сәбәпле капчыкка да ихтыяҗ азая. Бу күренешнең икенче нәтиҗәсе буларак, читкә акча эшләргә китүче чыптачыларның саны арта.

Шуңа карамастан, мунчала эшкәртүгә бәйле кәсеп Казан арты татар авыллары крестьяннары тормышында сизелерлек роль уйный. 1895 елда игенчеләрнең мул тормышын тәэмин итүдәге әһәмиятен аңлап, Казан губернасы земство оешмалары, кустарь җитештерүнең әлеге төренә ярдәм итү максатында, төрле чаралар оештыра. Моның өчен вак һөнәрчеләргә билгеләп куелган бәядән чимал сатып алу һәм сату буенча программа эшләнә, күпләп сату складлары булдырыла, шулай ук эшчеләрне алга киткән җитештерү техникасы белән таныштыру эшләре алып барыла. Күп кенә кустарьлар һәм сәнәгатьчеләр, тиз үзгәрүчән базар ихтыяҗларына җайлашып, үзләре дә яңа җитештерү ысулларына күчә башлый, хезмәт җитештерүчәнлеген арттыра торган яңа станоклар сатып алалар. Шуның ярдәмендә авыл халкы бу кәсепне саклап кына калмый, җитештерүне шактый алга җибәрә.

Яңа Шимбер авылы мисалында карап узыйк. 1899 елда авылда чыпта кәсебе белән 50 ир-ат, 20 хатын-кыз шөгыльләнгән. Аларның гомуми кереме 336 сум тәшкил иткән. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында Яңа Шимбер авылының иң эре чыптачылары дип Сафиулла Әхмәдуллин белән Галимҗан Шакирҗанов танылган. Һәр икесенең дә бишәр чыпта сугу станогы булган. Аларның кустарь производствосында унар кеше эшләгән, еллык сәнәгать әйләнеше – 2000 сум, кереме 200 сум булган.

Чыптачылар шактый кимесә дә, чыпта кәсебе XX гасыр башында да үз әһәмиятен саклый. Вак һөнәрчеләрнең чыпталарын әкренләп мануфактура һәм фабрика җитештергән товар кысрыклап чыгара. Чыптага ихтыяҗ кимү сәбәпле, Яңа Шимбердә традицион кәсеп сезонлы характер ала. Өч эшчедән торган бригаданың уртача айлык хезмәт хакы 7-8 сум тәшкил итә.

Тарихчы, галимә Тәэминә Биктимерова: «Әтнә районы авылларында сугыштан соңгы елларда (хезмәт көненә түләү булмаган вакытта) кешеләр чыпта сугу белән шөгыльләнергә мәҗбүр булды. Чыпта сугу эшенең авырлыгына җәфа чиккән әни: «Балаларым, бәхетегез чыптага кермәсен иде», – дип әйтә иде», – дип искә ала.

# Гасырлардан



# килгән көрәш

*Рабига МӘҺДИЕВА,*
*Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәгенең матди булмаган мәдәни мирас бүлегенең методисты*

*Көрәш — борынгы спорт төрләренең берсе, ул кабиләыру җыенында, бәйрәмнәрдә ярыш, тамаша буларак кереп китә, ә соңрак гаскәр сугышчыларын физик һәм рухи яктан ныгыту, тәрбияләү өчен кулланыла.*

Казан, 60 нчы еллар.
Татарстан Республикасы
Дәүләт архивы фондларыннан

Һәр халыкның борынгы заманнан алып, бүгенге көнгә хәтле нигезен тәшкил иткән, аны милләт буларак саклап калган, изге саналган мирасы бар. Татар халкында ул – җыр-моң, мәгърифәткә омтылу, китап, һөнәрчелек. Татар милли көрәше дә шушы рәттә.

Татар көрәше – милли спорт төре. Татар көрәшендә кул көчен кулланып, аяк чалмыйча көндәшеңне җирдән күтәреп алып, баш аркылы аркасына салырга кирәк. Милли көрәш Сабан туе, Җыен бәйрәмнәренең мөһим өлеше булып тора. Бөтенроссия көрәш ярышларында җиңүчеләргә спорт мастеры исеме бирелә.

Тарихка күз салсак, көрәшнең бик борынгыдан килгәнен күрәбез. Археологлар Россиянең төрле төбәкләрендә билбау белән көрәшүчеләр сурәте төшерелгән төрле савыт-саба, каешлар тапкан. Ә Алтайдагы борынгы кыя рәсемнәрендә төрле җанварлар аулау күренешләре белән беррәттән билбау көрәше, ат чабышы төшерелгәннәре дә табылган.

921 елда Багдадтан Болгарга илче булып килгән Ибн Фадлан хезмәтендә дә Сабан туе һәм көрәш тасвирлана. Гарәб сәяхәтчесе Әбү Хәмид әль Гарнати 1131 елда үзенең Болгарга килү сәяхәтнамәсендә көрәшче-пәһлеваннар, милли бәйрәмнәрдә үткәрелүче көрәш бәйгеләре турында мәгълүмат калдыра.

XI гасырга караган борынгы төрки әдәбиятында Йосыф Баласагунининың «Кутадгу билигъ» («Бәхетле булу») әсәрендә дә бил алышу тасвирлана. Төрки халыкларның «Алпамыш» һәм татар халкының «Идегәй» дастанында Нәүрүз, Сабантуй кебек төрки халык бәйрәмнәре һәм көрәш ысуллары шәрехләнә.





**Борынгы төркиләр көрәше.
Борынгы төркиләрнең көрәшен сурәтләгән ике бронза бляха, безнең эрага кадәр III-IV гасырлар // Грязнов М.П. Древнейшие памятники героического эпоса народов Южной Сибири // АСГЭ. – Л.: Изд-во Гос. Эрмитажа, 1961. – С. 7-31**

Борынгы Төрки кабиләләрдә һәм татарларда көнчыгыш көрәш сәнгате «Кара каплан» дип аталган. Тарихи яктан Болгар территориясе борынгы көрәш сәнгате «Кара каплан»ның ватаны булып санала, билбаулы көрәш аның бер төре булып тора. Танылган дәүләт эшлеклеләренең берсе Аксак Тимер (Тамерлан) XIV гасырда «Кара каплан» көрәш сәнгатен үз солдатларының физик әзерлеген яхшырту өчен кулланган.

Милли көрәшебезнең асылы гасырлар дәвамында сакланып, буыннан буынга тапшырылучы изге ядкәр булып, бүгенге көнгә кадәр килеп җиткән.

Көрәш ул – халыкның яшәү көчен, батырлыгын, кодрәтен күрсәтә торган спорт төре. Татарлардагы көрәш рухы бервакытта да югалмаган. Татарча көрәш бүген халкыбызны дөньяга таныту, кемлегебезне күрсәтү һәм дөньяның төрле почмакларында сибелеп яшәүче татарларыбызны берләштерү өчен дә хезмәт итә.

**Көрәш ул – халыкның яшәү көчен, батырлыгын, кодрәтен күрсәтә торган спорт төре.**



**Билбауда татар милли көрәше.
Рәссам һәм тарихчы Ф.Г. Солнцев открыткасы.
Акварель. 1869 ел**

**«Батыр калу» көрәштә башка көрәшчеләрне җиңеп, иң көчле булып танылуны аңлата.**

* * *

Сабантуйлар хәзер кыр эшләре тәмамлангач, табигатьнең иң хозур чагында башлана. Сабантуйда көрәш тәртибе түбәндәгечә оештырыла. Сабантуйда бил алышырга теләгән һәр көрәшче фамилиясен, исемен, туган елын, авырлыгын, эшләгән урынын күрсәтеп, үзе турында мәгълүмат бирә. Оештыручы көрәшчеләрне аерым төркемнәргә бүлеп, исемлекләр төзи. Катнашучылар күп булганда, очрашуларны олимпия системасы буенча, ягъни оттырган кеше шундук төшеп кала торган итеп үткәрәләр. Беренче әйләнештән соң көрәшчеләрнең яртысы гына кала. Алга таба көрәш шул ук тәртиптә, исемлектәге күрше белән күршенең очрашуы рәвешендә дәвам итә. Өч кенә көрәшче калгач, батырга көрәшү өчен бау белән шобага салу уздырыла. Әгәр көрәшче көндәшен җирдән (келәмнән) күтәреп, күкрәге, янбашы аша аркасына сала икән, бу чиста җиңү була. Көрәш бер якның да чиста җиңүе белән тәгәлләнмәсә, судьялар җиңүчене, көрәшнең сыйфатыннан, кайсы якның күпме балл җыюыннан чыгып билгели. «Батыр калу» көрәштә башка көрәшчеләрне җиңеп, иң көчле булып танылуны аңлата.

Күренекле язучы Мөхәммәт Мәһдиев «Бәхилләшү» романында Сабан туе күренешен, Арча районы Масра авылының данлыклы көрәшчесенең бил алышуын болай тасвирлый: «Сабан туенда кеше рухи киеренкелектән исергән, җирдән бераз гына аерылган. Кеше исәрләнгән. Әнә шундый исәрлекнең иң кызган бер мизгелендә кисәтүле, тирән мәгънәле ачы тавыш:

**Ташкент Сабан туенда. Сул якта Татарстан көрәшчесе. XIX гасыр ахыры. Татарстан Республикасы Дәүләт архивы фондларыннан**





**Сабантуйның төп ярышларының берсе – көрәш.**
**Казан, 1950 нче еллар.**
**Татарстан Республикасы Дәүләт архивы фондларыннан**

– Көрәшкә Курса корысы керде!

Вәссәләм. Бу инде – чын сәнгать башлана дигән сүз иде һәм Сабантуй шым калды. Менә мәйдан уртасына җиңел-җиңел генә атлап какча гәүдәле бер кеше керде – без шаккаттык! Бик җиңел сөякле күренде ул безгә, битләре кояшта янган, яңак сөякләре бераз чыгынкы, сакалы сирәк кенә, тәбәнәк кенә гәүдәле бер карт. Курса корысы каршында тирә-як Сабантуйларында батыр калып йөрүче буй сынлы Гыйззәт басып тора иде – Гыйззәтнең утыз яшьләр чамасы вакыты.

Халык сизми дә калды – саргылт сакаллы «Коры» яшен тизлеге белән Гыйззәтнең билен кызыл башлы сөлгесе белән урап алды да шундук һөҗүмгә күчте. Менә бер мизгелдә мәйдан уртасына иске тегермән җимерелгәндәй әллә ниткән корылдау тавышы таралды һәм Гыйззәт ике-өч метр читтә яшел үлән өстен-

**Казан, 1960 ел.**
**Татарстан Республикасы Дәүләт архивы фондларыннан**



**Чыганаклар:**
1. Ал-Гарнати А. Х. Путешествие Абу Хамида ал-Гарнати в восточную и центральную Европу (1131-1153 гг.): перевод с арабского. – Москва: Наука, 1971. – 136 с.
2. Баласагуни Ю. Наука быть счастливым: избранные главы поэмы. – Москва: Художественная литература, 1971 – 158 с.
3. Идегей: татарский народный эпос / Пер. с татарского Семена Липкина. – Казань: Татарское книжное издательство, 2019. – 269 с.
4. Ковалевский А. П. Книга Ахмеда Ибн-Фадлана о его путешествии на Волгу в 921-922 гг.: статьи, переводы и комментарии. – Харьков: Издательство Харьковского университета им. А. М. Горького, 1956. – 345 с.



**Бахчасарайның Сабан туенда. 1979 ел. www.liveinternet.ru/users/4768613/post385866232/**

дә ике аягын, ике кулын күккә күтәреп сырт белән ята иде. Коры үзе «менә көрәш шундый була ул» дигән сыман әйләнәдән чыгып китте».

Сабантуйның төп батырына элек-электән килгән йола-гадәт буенча тәкә бирәләр. Соңгы елларда башка төрле кыйммәтле бүләкләр бирү дә гадәткә керә башлады, ә шулай да тәкә бирү – ул Сабантуйның бер күркәм символы-бизәге. Батырның тәкә күтәреп мәйданны әйләнеп чыгуы үзе үк зур вакыйга.

* * *

Яшь буынны физик һәм рухи яктан көчле, чыдам, чын ир итеп тәрбияләү максатыннан, республикабызда көрәш секцияләре, спорт мәктәпләре эшли, даими рәвештә Татарстан, Россия күләмендә бәйгеләр үткәрелә.

2011 елда Татарстан тарихында беренче тапкыр милли көрәш буенча Казан шәһәрендә Дөнья чемпионаты узды. «Ак Барс» көрәш сараенда узган чемпионатта Корея, Иран, Таҗикстан, Беларусь, Молдова, Казахстан, Кыргызстан, Үзбәкстан кебек 27 илдән килгән 120 спортчы катнашты.

2020 елдан башлап Көрәш федерациясе Бөтендөнья этноспорт конфедерациясе составына керә. Конфедерация халыкара дәрәҗәдә милли һәм этник спорт төрләрен яңадан торгызу, саклау, үстерү һәм киң даирәгә тарату белән шөгыльләнә.

Быелның 21 маенда Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгы уңаеннан Шәһри Болгарда Дөнья Кубогына көрәш бәйгесе узды.

5. Крачковский И.Ю. Путешествие Ибн-Фадлана на Волгу / Академия Наук СССР; Институт Истории и Институт Востоковедения; пер. и коммент. под ред. И. Ю. Крачковского. – Москва: Издательство Академии Наук СССР, 1939. – 193 с.
6. М. Мәһдиев Бәхилләшү: Повесть. – Казан: Таткитнәшр., 1990. – 639 б.
7. Шәрәфетдинов Д. Р. Сабан туе – халыкның яшәеше: Фәнни-популяр очерк. – Казан: Гасырлар авазы, 1997. – 312 б.

*Земфира МӨХӘММӘТШИНА,*
*Апас халык театры режиссеры*

# Апас Сабан туена *рәхим итегез!*

(Сценарий)

***Сабантуй район мәдәният йорты каршындагы мәйданда уза. Кунакларны каршы ала торган җирдә арка куелган. Ул татар халкының орнаментлары белән бизәлгән һәм анда «Апас Сабан туена рәхим итегез!» дип язылган. Кунакларны милли чигешле сөлгеләр белән бизәлгән колга тоткан татар егете каршы ала. Аның янәшәсендә милли киемле кызлар-егетләр, бала-чагалар, гармунчылар басып тора. Берничәсенең кулында катык салынган җиз табак, чүлмәкләр, күкәй белән тулган кәрҗиннәр һәм чиләкләр. Кунакларга сөлге, яулык таратыла.***



**Алып баручы егет:** Хуш киләсез, мөхтәрәм кунаклар! Бүген Апасыбызда халкыбызның милли Сабантуй бәйрәме! Тик нинди бәйрәм ди ул, бүләксез?!

**Алып баручы кыз:** Элеккедән килгән гадәт буенча Сабантуй бәйрәменә атна буена бүләк җыйдык. Әби-бабайларыбызның изге теләкләрен тыңлап, хәер-фатыйхаларын алдык. Кемгә генә кермик, һәрберсенең теләге бер: елларыбыз имин булсын, кырларыбызда чәчелгән игеннәребез мул уңыш бирсен!

*(«Сабан туе – хезмәт туе» җыры астында кунаклар, ансамбльләрдән генә тезелгән коридор буйлап, татар, рус, чуваш халкының ишегалларына узалар. Чыккач махсус тезеп куелган утыргычларга утыралар.*

*Җылы яклардан кайтып килүче кошларның һәм челтерәп аккан су тавышлары ишетелә. «Фазыл чишмәсе» җыры астында бер төркем кызлар, чишмәгә суга төшкән булып, көянтә-чиләкләрен асып, мәйданга керәләр. «Елга» зәңгәр тукымадан ясала. Тукыманың ике башыннан тотып, балалар елганы «дулкынландырып» торалар.)*

**Алып баручы 1 нче кыз:** Кызлар, карагыз әле, җылы яклардан кошлар кайта! Кыр казлары!

**Алып баручы 2 нче кыз:** Безгә бәхетләр генә алып кайта күрсеннәр инде!

**Алып баручы 3 нче кыз:** Байлык, муллык, иминлек, саулык алып кайтыгыз, җанашларым!

*(Кызлар биюе күрсәтелә. Алар «елгадан» чиләкләре белән су алалар. Җыр ахырында кызлар мәйданнан чыга. Бер кыз торып кала. Ул каударланып, борчылып «судан» нидер эзли.«Татарча лирик көй» яңгырый.)*

**Алып баручы кыз:** Елгага бер сыңар алтын алкамны төшереп җибәрдем. Ничекләр генә су төбеннән эзләп табарга инде. Әтием бүләге иде...

**Ерактан бабай тавышы яңгырый:** Борчылма кызым, авылыгызның бик булдыклы Габбас исемле егете алкаңны табып бирер. Тик син миңа ул егеткә кияүгә чыгарга вәгъдә бир. Шушы сулык буенда урнашып яшәгез. Бу суны, алкаң табылган хөрмәткә – «Табар», ә сез урнашкан урынны Габбас егет хөрмәтенә – «Апас» диеп атагыз. Сезне дәвам иткән буыннар чылбыры бик озын һәм бәхетле булыр!

**Алып баручы егет**: Бу вакыйга 1647 елда була. Алтын алкасын су төбеннән табып биргәч, аксакалның сүзләренә колак салып, кыз егеткә кияүгә чыгарга ризалыгын бирә. Яшьләр өйләнешеп, бергә гомер итә башлыйлар. Нәкъ тә шул чорда Габбас сүзеннән барлыкка килгән Апас исемле авыл калкып чыга. Габбас табигый сулыкларга бик игътибарлы кеше булган диләр. Бүгенге көндә дә аның хөрмәтенә атап әйтелгән Әппәз күлләре һәм Апасыбыз уртасыннан дулкынланып, бәргәләнеп агучы 347 еллык Табар елгасы Апас халкы күңелендә тарихи вакыйга булып саклана...

**Алып баручы кыз**: Җиһанга янәдән язлар килде. Тормыш дәвам итә... Габбас ага дәвамчылары – Тау ягының горур халкы игенчелек, терлекчелек өлкәсендә алдынгылардан санала. Бердәм халкым быел да чәчү эшенә кереште.

*(Чәчү күренеше биюе. «Иртәнге нур» (Сара Садыйкова көе, Зиннәт Вәли сүзләре) җырын «Зиләйлүк» вокаль ансамбле башкара.)*

**Алып баручы егет:** Чәчү тәмам... Елыбыз нинди булыр? Вакытында яңгыры да, кояшы да булсын иде.

**Алып баручы кыз:**
Җир-Анабызда шытадыр,
усәдер изге икмәк,
Яшәү өчен һәр кешегә
иң татлы икмәк кирәк!
Җиң сызганып эшләп аргач,
бәйрәм уздыру кирәк,
Сабан тәмам! Шулай булгач –
безгә Сабантуй кирәк!







*(«Сабантуе – хезмәт туе» җырын җырлап, колга тоткан яшьләр, гармунчылар, ансамбльләр мәйданга керә. Аннары «Сөлге чигәм» җыры яңгырый. Чиккән сөлгеләрен тотып кызлар бии.)*

**Алып баручы кыз:**
Оста кызлар Сабантуйга
Матур сөлге чигәләр.
Көрәштәге батырларга
Бүләк итеп бирәләр.
Ә сөлгеләр бизәк кенә,
Чәчәк белән бер алар.
Мәхәббәт хисләре белән
Чигелгәннәрдер алар.

*(Гөлия Шиһабиева «Эх, Сабантуй» җырын башкара. Җыр барышында «капчык белән сугышу», «кашыкка йомырка салып йөгерү», «чүлмәк вату», «капчык киеп йөгерү» уеннары күрсәтелә.)*

**Алып баручы егет:** Сабантуй кызганнан-кыза гына, дуслар. Сабантуйның асыл ташы булган тагын бер ярыш, ул да булса – ат чабышы. Авылда үсеп, ат җигеп, яки атка атланып йөргүнең тәмен бер татысаң, аны онытырга мөмкин түгел. Күп кенә төрки халыкларда, егет-кыз ярәшү вакытында, егет кызга тиң булуын атта узышып расларга тиеш булган. Әгәр куып җитеп, кызны үз кочагына ала икән, ул лаеклы кияү саналган. Инде моны булдыра алмаса, бөтен кеше алдында хурлыкка калган. Ат чабышлары бүгенге көндә дә Сабантуйның бизәге булып тора.

*(Шул вакыт бер әби кулына чиккән сөлге тотып керә.)*







**Әби:** Соңга калмадыммы? Ии-и-и, Аллага шөкер, өлгердем бит, ә ?! Менә, балалар, берүк нәзер сөлгесен оныта күрмәгез.

**Алып баручы кыз:** Әби, син нинди нәзер сөлгесе турында сөйлисең?

**Әби:** Ат чабышында алдан килгән атны гел мактыйлар. Әмма иң ахырдан килгән атны да кимсетергә ярамый. Ел саен Сабантуйлар узгач: «Киләсе елда ярышта соңга калып килгән атка һәм аның хуҗасына сөлге чигәм», – дип нәзер әйтә торган гадәтем бар. Әлхәмдүллилләһ, өлгерттем бит! Минем исемнән тапшырырсыз үзенә.

**Алып баручы:** Аңлашылды, әби! Рәхмәт, сиңа бүләгең өчен.

*(Музыка алышына. Көрәшчеләр өчен көй куела. Мәйданда көрәш башлана. Ике егет көч сынаша. Тирә-ягында җанатарлар көч биреп торалар.)*

**Алып баручы кыз:** Көч-куәтле кешеләргә татарда элек-электән зур хөрмәт булган. Сабантуй батыры исә авылда иң абруйлы кеше саналган. Аңа кунакта урынны иң түрдән биргәннәр, исемен зурлап телгә алганнар.

**Алып баручы егет:** Кызлар да бит Сабантуй батырына кияүгә чыгуны үзләре өчен олы бәхет дип санаганнар.

**Алып баручы кыз:** Бүген дә мәйдан уртасында Апасыбызның батыр егетләре көч сынаша.

Көрәш кыза мәйдан уртасында,
Дулкынлана халык, кем җиңәр?!
Көрәшчеләр әле сер бирмиләр,
Чыдасыннар гына сөлгеләр!

*(Егетләрнең берсе тиз генә икенчесен күтәреп сала. Батыр калган егетне дуслары «күккә чөя». Батыр калган егет янына чиккән сөлгесен тотып бер кыз килә. Сөлгене егетнең җилкәсенә сала.)*

**Алып баручы кыз:** Татарстанның бик матур бер почмагында урнашкан, Тәтеш, Кама Тамагы, Буа, Югары Ослан районнары белән чиктәш булган, кечкенә генә Апасыбыз үзенең олпат шәхесләре белән дөньяга танылган. Калфаклы сандугачыбыз, моң чишмәбез, нуры сүнмәс шәхесебез, хатын-кызлар арасында беренче композитор Сара Садыйкова үзе генә дә ни тора! Сара Гариф кызы Садыйкова татар опера сәнгатенә нигез салучыларның берсе, халкыбыз күңелендә лаеклы урынын тапкан йөзләрчә җырлар авторы, 60 елга сузылган иҗади эшчәнлегенең үзәгендә кайнаучы, төрле жанрдагы спектакльләргә җырлар, музыкаль комедияләргә соклангыч әсәрләр язучы олы шәхес. Ул һәрчак безнең күңелләрдә.

**Алып баручы егет:** Мәшһүр опера җырчылары Бану Вәлиева, Фәхри Насретдинов, театр өлкәсендә югары үрләр яулаган Алсу Гайнуллина, Илсөя Төхвәтуллина, Люция Галләмова, Илдус Габдрахманов, шулай ук халык артистлары Фердинанд Сәлахов, Илсур Сафин – районыбыз горурлыгы.

*(Фердинанд Сәлахов җыр башкара.)*

**Алып баручы егет:** Җыр белән бию янәшә бит ул, дуслар. Мөхтәрәм кунаклар, сезнең каршыгызда Галиәсгар Камал театры актеры, Татарстанның халык артисты, Апас егете Илдус Габдрахманов һәм аның тормыш иптәше Сәлимә Әминова! Сәлимә Салават кызы Камал театры балетмейстеры. 30 еллап гомерен Камалчыларга багышлый. Һәрбер актердан биюче ясый ул.

*(Илдус Габдрахманов һәм Сәлимә Әминова чыгышы.)*

**Алып баручы егет:**
Сабантуй ул гаҗәеп зур бәйрәм,
Сабантуй ул безнең борынгы.
Сабантуй ул берләштерә безне,
Һәм ныгыта бөтен районны.

**Алып баручы кыз:**
Апасыбыз горурлыгы бит ул
Төрле милләт бергә янәшә.
Рус, татар, чуваш халкы һәрчак
Бердәм булып бәхет өләшә.

Фоторәсемнәр авторның шәхси архивыннан

*Рәмзия ХӨСӘЕНОВА,*
*Кукмара, Зур Сәрдек авылы клубының сәнгать җитәкчесе*



Рушан Якупова. «Яңа самовыр» рәсеме фрагменты.

# САМАВЫР *бәйрәме*

**КУКМАРА РАЙОНЫНЫҢ ЗУР СӘРДЕК АВЫЛЫНДА 1990 ЕЛДАН БИРЛЕ САМАВЫР БӘЙРӘМЕ УЗДЫРЫЛА. САМАВЫР ГАИЛӘНЕҢ МУЛЛЫК, ИМИНЛЕК БИЛГЕСЕ БУЛГАН КЕБЕК, БӘЙРӘМЕ ДӘ АВЫЛ ХАЛКЫН БЕРЛӘШТЕРӘ, БУЫННАРНЫ ТОТАШТЫРА ҺӘМ ҖИРЛЕ ФОЛЬКЛОРНЫ САКЛЫЙ.**



*Авылның барлык чишмәләреннән су алына. Самавырлар нарат күркәсе белән кайнатыла. Чәй табынына милли ризыклар куела.*

Әле кайчан гына көл һәм ком белән ышкып ялтыратылган самавыр һәр йортның өстәл түрендә балкып тора, ул кыз бирнәсенә дә керә, мирас булып та кала иде. Хәер, самавыр әле дә музей экспонаты түгел, урам бәйрәмнәрендә, яшьләр пикникларында, гаилә бәйрәмнәрендә ул һәрвакыт табын түрендә.

Зур Сәрдекнең Самавыр бәйрәмен әзерләү берничә этаптан тора:

– урам сәхнәсе һәм тамашачылар өчен урыннары булган бәйрәм мәйданчыгы ясала, чәй өстәлләре бизәлә;

– самавыр тарихына караган мәгълүматлар туплана, самавырлар фотокүргәзмәсе оештырыла;

– туган якка багышланган җырлар һәм кич утырулар, чәй табыннары турында шигырьләрдән, милли йолалар турында хореографик композицияләрдән торган концерт номерлары әзерләнә;

– тамашачылар өчен шаян бәйгеләр, әйлән-бәйләнле уеннар оештырыла.

Бәйрәм азагында авылдашлардан җыелган күчтәнәчләр белән чәй табыны корыла.

Бәйрәм уздыру өчен уңайлы урын сайлана. Җигүле атлар бизәлә. Бәйрәм буласы урынга авыл яшьләре җигүле атларга төялеп килә. Яшьләр тарафыннан башкарылучы халкыбызның үлмәс «Тимер чана», «Күбәләгем», «Алтын алка», «Дим-Дим» кебек җырлары бәйрәм рухы өсти.

Җилфер-җилфер, дим-дим,
Йөргән чакта, дим-дим,
Җилләр ача куенымны.
Янып-көеп, дим-дим,
Йөргән чакта, дим-дим.
Дуслар ача күңелемне.
Җилфер-җилфер, дим-дим,
Итүе лә, дим-дим,
Җилнең алып китүе.
Күңелле дус, дим-дим,
Ишләр белән, дим-дим,
Бергә гомер итүе.

Авылның барлык чишмәләреннән су алына. Самавырлар нарат күркәсе белән кайнатыла. Чәй табынына милли ризыклар куела. Өстәлдәге сый арасында безнең авылда яратып пешерелә торган чәй токмачы да була. Аны бары тик бездә генә бар нечкәлекләрен белеп пешерәләр.

Чәй токмачы өчен камырны йомырканың сарысыннан гына әзерлиләр. Камыр йомшак булырга тиеш. Камырны җеп калынлыгында җәяргә кирәк, югыйсә, калын камыр майны үзенә сеңдерә. Тагын бер мөһим серне ачабыз – җәймәне артык онларга ярамый, югыйсә кыздырган вакытта он карала, чәй токмачының төсе матур булмый. Камырны матурлап кисеп кызган майда пешерәбез. Камыр кисәкләрен күпләп салырга ярамый, чөнки астагылары кабармыйча калырга мөмкин. Суынганчы чәй токмачы өстенә шикәр комы сибәбез.

*«Татар халкында «Самавыр бәйрәме» дигән бәйрәм булмаса да, самавыр кайнап, өстәлгә килгәч, һәр йортка бәйрәм төсе керә торган булган».*

* * *

Бу бәйрәмдә һәркемне җыр-бию, сый-хөрмәт, самавыр чәе, борынгы уеннар көтә. Кунакларны матур такмаклар әйтеп каршы алалар.

Якын дуслар килгән безгә,
Төшмәенчә диңгезгә.
Кадерле кунак сез безгә,
Ни хөрмәт итик сезгә?

Хөрмәтебез шул булыр –
Чәе-ашы мул булыр.
Табыннарыбыз түрендә
Самавыры, чәйнеге,
Чәркәсе, пыяласы.
Әйдә, дуслар, бәйрәм итик,
Бүген шундый чарасы.

Самавыр торбаларыннан
Төтен чыга бөркелеп.
Тамашага җыелганнар,
Торалар шау-гөр килеп.

Самавырдан кайнар чәйне
Эчкән һәр милләт халкы.
Базарларда кыйммәт булып,
Йөргән самавыр хакы.

Сусаганны да баскан ул,
Өеңне дә җылыткан.
Арган тәнгә шифа булган,
Чәе кышкы суыкта.

Әй, самавыр, самавыр,
Тарихларда каладыр.
Ә самавыр бәйрәмебез
Җырлап-биеп барадыр.

* * *

Алып баручы кунакларны самавыр һәм чәй тарихы белән таныштыра: «Чәй өстәленең аерылгысыз бизәге – җиз самавыр. Аны агач күмере, шакмара, кипкән нарат күркәләре белән кайнатканнар. Чәйне тәмле итеп төрле үләннәр салып ясый торган булганнар. Үзебезнең якларда үсүче – мәтрүшкә, бөтнек, юкә чәчәге, төрле җиләк-җимеш куакларының яфраклары салынган чәйләргә өстенлек бирелгән.

Татар халкында «Самавыр бәйрәме» дигән бәйрәм булмаса да, самавыр кайнап, өстәлгә килгәч, һәр йортка бәйрәм төсе керә торган булган. Келәт почмакларында моңаеп утыра торган самавырларны без бүген кояшка чыгардык. Ничә еллар буена тыныч кына яткан, һәр өлкән хуҗабикәгә бик газиз булган самавырлар көлеп җибәргәндәй булды, җырлашып кайнарга әзерләнәләр».

Безнең авыл – зур авыл,
Капка саен каравыл.
Аш артыннан чәй эчмәгәч,
Нәрсәгә ул самавыр.
Самавыр куйдым күмерсез,
Кайнап чыгар күрерсез.
Бездә Самавыр бәйрәме,
Булмас бүген күңелсез.

* * *

Бәйрәм кечке уеннарда, утырмаларда уйналына торган җыр-биюле уеннар белән дәвам итә. Мәсәлән: «Наза», «Биш парлы», «Гөлбану», «Бармаклы», «Бормалы» уеннары шундыйларга керә.















«Бармаклы» уены безнең якларга гына хас. «Бармаклы» уйнау өчен яшьләр ярымтүгәрәкләнеп тезелеп баса. Уртада берәү бармак санаучы булып кала. Һәркем бишбармагын куя. Бармакларга чиратлашып басып, мәхәббәт такмакларын башкаралар. Җыр кемдә тукталса, аның эчтәлеге шул кешегә кагыла һәм ул санаучы булып кала. Уен шулай дәвам итә. Бу уенны безнең авылда аулак өйләрдә дә, кырда эштән арып ял итәргә туктагач та уйный торган булганнар. Мондый уеннар милли традицияләрне саклап калуга да зур өлеш кертә. Бу уенда кулланыла торган такмаклар:

Кәүсәрия, дип язылган,
Кулъяулык почмагына *(2 тапкыр)*.
Син дә кермә, мин дә кермим,
Җиде ят кочагына.

Урак белән чүкеч төшкән
Совет ачкычларына,
Икәү бергә бассак иде,
ЗАГС баскычларына.

Торна төшкән, торна төшкән,
Торна төшкән борчакка.
Үзем түгел, сүзем әрәм,
Син, апара корсакка.

Военныйлар яшел кия,
Чирәмдә күренмәскә.
Салдың гыйшык утларына,
Сүнмәскә, сүрелмәскә.

Ике аккош очып бара
Күлнең түгәрәгенә.
Син дускайны ошатамын,
Оҗмах күбәләгенә.

Челтәрле күпер астында,
Алмалы поднос юдым.
Ал кулыңа, сал куеныңа
Мин синең өчен тудым.

Челтәрле күпер астында
Катлам-катлам кара таш.
Сагындырмас дигән идем,
Сагындырды кара каш.

**Чыганаклар:**
1. Бакиров М.Х. Татар фольклоры. – Казан: «Мәгариф» нәшрияты, 2008.
2. Татар халык иҗаты. – Казан: РИЦ «Школа», 2005.
3. Урманче Ф. Татар халык иҗаты. – Казан: «Мәгариф» нәшрияты, 2005.
4. Яхин А.Г. Система татарского фольклора. – Казань: Татарское книжное издательство,1984.
5. Татар халык иҗаты. – Казан: «Мәгариф» нәшрияты, 2004.

Фоторәсемнәр авторның шәхси архивыннан

*Евгения ШЕМЕЛОВА,*
*Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге методисты*

# Буыннар хәтерен саклагыз!



**Талант иясе үз иҗатына миллилек кертеп кабатланмас матурлык тудыра ала. Декоратив-гамәли сәнгать өлкәсендә республикабызның танылган рәссамнарыннан берсе Наилә Галәвиева иҗатына нәкъ менә милли колорит хас. Ә миллилек — чын сәнгатьнең алыштыргысыз өлеше.**



«Әби». 2005 ел



«Иң зур байлык – туганлык». 2020 ел



«Яучы»

Наилә Әмин кызы Казан сынлы сәнгать училищесының педагогика бүлеген һәм Чуваш педагогика институтының сәнгать-графика факультетын тәмамлаган. 2006 елдан бирле Казан илкүләм тикшеренү технология университетында (КНИТУ) укыта, «Дизайн» кафедрасы доценты.

Педагогик эшчәнлегеннән тыш, Наилә ханым декоратив сәнгать өлкәсендә актив иҗатчы – ул татар милли стилендә текстиль сувенир курчаклар һәм корама паннолар ясый. Паннолар өчен авторлык техникасын булдырган – грунтланган текстиль куллана.

Рәссамның эшләре татар әкиятләренә, халкыбызның милли бәйрәмнәренә һәм йолаларына, татар авылы көнкүрешенә багышланган. Татар фольклорын, этнографиясен, халык мәдәниятен тирәнтен белүе персонажлар костюмының һәм йорт интерьерының һәр детален нечкәләп ясарга мөмкинлек бирә, күргәзмәләренә килгән тамашачыны да, татар декоратив-гамәли сәнгать белгечләрен дә сокландыра.

Аның курчаклары милли киемле сувенирлар гына түгел, холкы һәм яшәү рәвеше күрсәтелгән шәхесләргә тиң. Мәсәлән, «Әби» курчагын алыйк. Аның татар сандыгы да, кулдан бәйләнгән паласы да, кулында дисбесе дә бар. Киеменең һәр элементы гаҗәеп төгәллек белән тегелгән, аякларына ак оекбашка кадәр кидертелгән! «Мәйсәрә», «Ахирәт әбиләр», «Колакка кергән сүзләр» һәм башкалар – барлыгы иллеләп курчакның һәрберсе үзенчә.



«Мәйсәрә». 2002 ел



«Уйна, гармун!» 2010 ел



«Кое янында». 2009 ел



«Мәдрәсәдә»



«Бишек жыры»

«Кое янында» корама панносы елмайта. Авылда яшәгән яки кунакка кайткан кешегә таныш күренеш: коега су алырга чыккан күрше хатыннары гәпләшеп дөньяларын оныткан – чиләкләрендә казлар коена, ә алар сөйләшәме-сөйләшә.

«Хуҗалык мәшәкатьләре», «Уйна, гармун», «Чәй табыны», «Галушлар», «Шаярту» «Йолдызчыклар», «Мунчада», «Әби кчүтәнәче», «Төнге күзәтү», «Әни», «Әби бәлеше», «Әкияти урман», «Шаяннар», «Тынгысыз», «Булышчы», «Күршеләр», «Беренче кар», «Җәй» һәм башкалар – болар барысы да авыл тормышын тасвирлаган якты картиналар.

«Балачагым Биектау районының Зур Көек авылында узды. Авыл көнкүреше һәм аның кешеләре шуңа да бик якын, – ди Наилә Әмин кызы. – Панно идеяләре юктан бар булмаган, барысы да таныш күренешләр, персонажлар да таныш кешеләр».

Наилә Галәвиеваның «Туган йорт җылысы» дип аталган беренче шәхси күргәзмәсе тамашачыда кызыксыну уятты. Күпләрнең – гади тамашачының да, күренекле шәхесләрнең дә – балачагы авылда узган ләбаса, күбесе шунда туып үскән. Күргәзмә исеме республиканың беренче Президенты Минтимер Шәймиев бәяләмәсеннән алынган – рәссамның



«Сувенир курчаклар». 2014 ел



**«Чәй табыны». 2011 ел**

эшләре аның күңелендә якты хатирәләр уяткан. Халык шагыйре, мәрхүм Роберт Миңнуллин, Наилә Галәвиева иҗаты белән рухланып, унҗиде шигырь язган. Хәзер рәссам күргәзмәләрен әлеге шигырьләр белән тулыландыра.

Рәссамның эшләре Татарстанда гына түгел, Франциядә, Германиядә, Екатеринбургта, Чиләбедә, Мәскәүдә, Түбән Новгородта, Саранскида, Чабаксарда төрле күргәзмәләргә куелган.

«Минем эшләремне күргән яшьләр авылларны сакларга алынсын иде. Авыл бетсә, традицияләр дә, тел дә, җырларыбыз да югалырга мөмкин. Халык мәдәниятен һәркем белергә тиеш. Тамырлардан аерылмыйк. Буыннар хәтере югалмасын», – ди рәссам.

Фоторәсемнәр Наилә Галәвиеваның шәхси архивыннан

**Панно – авторлык техникасын кулланып эшләнгән күләмле аппликация. Кулланылучы материаллар: ДВП, тукыма, ПВА җилеме, синтепон, картон, костюмнар һәм панно кырларын бизәү өчен декоратив тасмалар, акрил буяулар. Персонажларның йөзе һәм куллары грунтланган текстиль техникасында ясалган.**

# БӘҺИҖӘ АПА КАЛФАГЫ



Авылыбызның ак әбисе Бәһиҗә апа Латыйпованы сарманлылар халкыбызның иң затлы баш киемнәре – калфак белән түбәтәй эшләү остасы буларак белә. Без бу язмада Бәһиҗә апаның тормыш юлын һәм үз куллары белән матурлык тудыра белүче күп яклы оста булуын ачарга тырышырбыз.

Бәһиҗә Габделхак кызы Латыйпова 1937 елның 28 февралендә Таулы Дөреш авылында туа. 1941 елның февралендә абыйсы Габбасны Мәскәүдә ФЗӨда укыган җиреннән армиягә алалар. Күп тә үтми сугыш башлана. Абыйсы шул китүеннән эзсез югала. Сугыш елларында берәүгә дә җиңел булмый. Авыл халкы ачлытуклы яшәсә дә, фронт өчен көченнән килгәнчә өлеш кертә: көне буе арып-талып эшләп кайтуларына карамастан, кич утырып, чыра яктысында оекбаш-бияләйләр бәйлиләр. Кич утырулардан кечкенә Бәһиҗә дә читтә калмый. Авыл апайлары аны урындыкка бастырып җырлаталар, үзләре елый-елый кул эшләре эшлиләр. Бәһиҗә баштарак аларның елауларына аптырый. «Әллә инде минем җырлаганны ошатмыйлар микән, дип, тырышыбрак җырлый идем. Үзем, кумасалар ярар иде дип, курка идем. Ә инде апалар: «Син җырлагач, безнең йокы килми, тагын берне генә булса да җырла инде», – дигәч, мин сөенә-сөенә җырлый идем», – дип искә ала балачагын Бәһиҗә апа.

1944 елның сентябрендә Бәһиҗә беренче сыйныфка укырга керә. Укытучы Мәрзия апасы аны беренче булып сәхнәгә алып менә, кыз бала спектакльләрдә төп рольләрне башкара. Аның уеныннан солдат хатыннарының күз яшьләре авыл клубының салкын идәненә тама. Җиденче сыйныфны тәмамлагач, Бәһиҗәнең алга таба укыйсы килсә дә, очын-очка ялгап яшәгән гаилә өчен бу мөмкин булмый. Шулай итеп үсмер кыз колхозда сөт җыючы булып эшли башлый. Атны үзе җигә, бидоннарны үзе күтәрә, үзе төшерә. Бик авыр булса да сынатмый, җыр белән юана. «Үз күңелеңне үзең күрсәң генә яшәп була иде. Мине җыр коткарды, юанычым да, шатлыгым да булды», – дип искә ала ул елларны сәхнә ветераны.

Бәһиҗә апа сәхнә тормышын сайлаган булса, бәлки, тагын бер Сарман сандугачы булыр иде. Аның «Рамай», «Сарман», «Тәфтиләү», «Зөләйха», «Гөлмәрфуга» җырларын ишеткәннәр тыныч кына тыңлый алмый. Аңардагы моң, саф, чиста тавыш танылган артистларныкыннан бер дә ким түгел.

Бәһиҗә апа булачак ире Закир абый белән, Югары Чыршылы авылына кунакка баргач, кичке уенда таныша. Бу танышу аларны мәңгелеккә кавыштыра. Яшь гаилә берничә ел авылда яшәгәч, Чаллы шәһәренә күченә. Биредә Бәһиҗә апа шәһәрнең ГЭС бистәсе мәдәният йортында узган концертларда, спектакльләрдә өздереп җырлый башлый. Сәхнә тормышыннан гел китмәс иде дә, вакыт җитми – гаиләдә өч бала үсә, ә көндезләрен эштә була. Яраткан кул эшләрен дә онытып бетерәсе килми. Бу осталыгы мәдәният йорты хезмәткәрләрен кыен хәлләрдән дә алып чыга. «Зәңгәр шәл» спектакле белән Казанга барырга кирәк, Чаллыда калфак таба алмыйлар. Менә шунда Бәһиҗә апаның калфагы бик тә ярап куя.

Лаеклы ялга чыгарга биш ел калгач, аны Чаллы шәһәре Пионерлар йортына эшкә чакыралар. Ул анда «Айгөл» татар милли чигү түгәрәген җитәкли. Белгәннәрен башкалар-

га өйрәтү аңа рәхәтлек кенә бирә. Остаyның мәртәбәсе шәкертенә карап, диләр бит. Бәһиҗә апа да үз һөнәренә мәхәббәт уята алган укучылары белән горурлана.

Бәһиҗә апа калфаклар, кәттәҗиләр, түбәтәйләр эшләү буенча зур фәнни эшләр язган белгечкә тиң: аларның тарихын, эшләү ысулларын һаман өйрәнә. «Казан арты калфагы үзенчә, Чаллы ягында бөтенләй башка. Минзәлә, Зәй, Сарман яклары сәйлән белән чигә. Керәшен татарларында исә ак төс юк, аларда көмеш ука, көмеш тәңкә өстенлек итә. Ак калфак бары тик татарныкы гына, ак энҗе, ак сәйлән белән чигү бездә генә. Башка бер генә милләттә дә ак төс белән чигү юк. Башка төрки халыкларда ул башка төстәге сәйлән белән чигелә. Ак калфак өлкәнрәкләр өчен, ә үсмер кызларга кәттәҗиләр күркәм», – ди калфак чигү остасы.













Бәһиҗә апа гомер буе өйрәнә һәм белгәннәрен кешеләргә өйрәтә. Әз генә буш вакыты булдымы, кулына энә-җеп ала. Чигү бит ул күңелгә рәхәтлек бирә, тынычландыра. Калфак һәм түбәтәйләрне искелек калдыгына санап, оны-тырга да тырышып карадылар. Ә аларны нәкъ Бәһиҗә апа кебекләр саклап калды. Аның коллекциясендә кәттәҗи, калфак, түбәтәйләр белән беррәттән башмаклар, бияләйләр, шәлләр, чигүле сөлгеләр, кулъяулыклар, кулдан тегелгән, татар бизәкләре белән чигелгән сумкалар, урындык япмалары һәм башка кирәк-яраклар бар.

Бәһиҗә апа өлкән яшьтә булуына карамастан, һаман хәрәкәттә, нидер эзләнә, нидер эшли. Тырышлыкларының әҗерен күреп, балаларының кадер-хөрмәтендә, озак гомер итәргә язсын.

**Гүзәл ХӨСНЕТДИНОВА,**
**мәдәният йорты директоры,**
**Әлфия ГЫЙЛЬМАНОВА,**
**сәнгать җитәкчесе.**
**Сарман, Югары Чыршылы авылы**

# КУЛЫМДАГЫ КУРЧАГЫМНЫҢ ИСЕМНӘРЕ ФАТЫЙМА

Мин, Татарстанның Әгерҗе районы Көчек авылында туып үскән, гади бер кыз. Бүгенге көндә Әгерҗе шәһәрендә яшим. Китапханәдә эшлим.

Мин матурлыкка гашыйк, кечкенәдән рәсем төшерергә яратам. Балачагымда әлләниләр уйлап чыгарып ясый идем, юк кына нәрсәләр дә миңа бик матур тоела иде. Безнең заманда кайсы гына кыз бала курчаклы уйнап, аларга күлмәкләр текмәгән икән?! Мин дә курчак уйнап, чүпрәк кисәкләреннән курчакларыма күлмәкләр тегеп үстем. Балачакның шушы матур бер уены хәзер яраткан шөгылемә әверелер дип кем уйлаган – мин хәзер дә курчакларга киемнәр тегәм. Олы кешегә кием тегүгә караганда да катлаулырак ул курчак киендерү – зур түземлек сорый. Әмма миңа бу бик ошый.

Кызымның балачактагы курчакларын ташламаган идем, шуларны эшкә җиктем. Таныгансыздыр инде – заманында балалар яратып уйнаган Барби курчаклары болар. Пластик шешәне кисеп, курчакны шунда утырткач, ул басып тора. Озын күлмәк кидергәч, шешә күренми, итәк матур булып кабара.





Минем һәр курчагымның исеме бар. Никах күлмәгендәге курчагым Фатыйма исемле. Монысы – «Беренче театр» спектаклендәге Биби. Аш-су остасы – Җәмилә. Бу гүзәл кыз – Айсылу. Исемнәрне киемнәренә туры китереп сайлыйм. Яшь чуваш гаиләсе – Микулай белән Ассоль, татар гаиләсе – Кәрим белән Сылу, удмурт кызы Любовь, рус кызы  Екатерина.

Районда «Ак калфак» оешмасы эшли башлагач, тагын бер шөгылем барлыкка килде – калфаклар тегеп чигә башладым.





**Чулпан НУРМӨХӘМӘТОВА,**
**Әгерҗе шәһәре**

*Лилия МӨХӘММӘТҖАНОВА,*
*филология фәннәре докторы,*
*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре*

# *Тыпыр-тыпыр биегәндә...*

(ТАТАР ХАЛЫК ИҖАТЫНДА УЕН ҺӘМ БИЮ ТАКМАКЛАРЫ)



**«Бишле бию». Татарстан Республикасының Дәүләт җыр һәм бию ансамбле. https://art16.ru/gallery2/v/WhatInKazan/filarmoniada-2010/hazine/06936.jpg.html?g2_imageViewsIndex=1**

**ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ ҖЫР МИРАСЫНДА УЕН-БИЮ ҖЫРЛАРЫ ЗУР УРЫН АЛЫП ТОРА, Ә УЕН-БИЮ ҖЫРЛАРЫНЫҢ ТӨП ӨЛЕШЕН ИСӘ «ТАКМАКЛАР» ДИП АТАЛГАН ЖАНР ТӘРЕ БИЛИ. ЧАЛ ТАРИХ АВАЗЛАРЫ ДА, БҮГЕНГЕ КӨННӘР АҺӘҢЕ ДӘ ТИРӘН УЕЛГАН КӨЙЛЕ ҺӘМ СҮЗЛЕ ГҮЗӘЛ БУ ЯДКӘРЛӘР, ҺИЧШИКСЕЗ, АЕРЫМ ӘҺӘМИЯТКӘ ЛАЕК.**

## ТАКМАКТА ДА ХИКМӘТ БАР

Такмаклар – татар халык музыкаль-поэтик фольклорының йолалар вакытында көйләп такмаклау стилендә башкарыла торган уен элементына ия жанры, халык иҗатында күңел ачу, бәйрәм итү белән бәйле йола фольклорында, эпик җыр сыйфатында эпос тукымасында бик еш очрый. Бу – килеп чыгышының борынгылыгы белән үк игътибарны җәлеп итә торган әсәрләр. Алар кешелек дөньясының сабыйлык чорында ук, җыр-биюгә, хезмәт эшчәнлегенә һәм йолаларга кушылып, музыка коралларына кадәр үк барлыкка килгән һәм, киң таралып, музыканы алыштырып яшәгән. Бию такмакларының тамырлары, һичшиксез, мәҗүсият чорына – шаман хәрәкәтләре вакытында әйтелә торган ритмик текстларга һәм биюләргә үк барып тоташа, музыка коралыннан бәйсез башкарылган күмәк культ-биюләр заманнарын колачлый.

Билгеле булганча, фольклор әсәренең төп билгеләреннән берсе – синкретиклык, йола комплексында очрый торган җыр-такмак текстлары да – әнә шул җитди билгенең күркәм мисалы. Йола фольклоры поэзиясе һәм уен-бию такмаклары – җыр жанрының йола яки уен барышында реальләшә торган төре. Нәкъ менә шушы аерылгысыз бәйләнештә булу сыйфаты, ягъни күптөрле нәүрүзләрнең, келәүләрнең, сөрәннәрнең, арбауларның һәм сыктауларның, такмак-такмазаларның һәм җырларның теге яки бу йола, уен барышына логик һәм эстетик бәйләнгән булуы, аларның шул бәйләнештән башка җанлы яшәештә бик сирәк очравы бу катлаулы иҗат дөньясының уртак сыйфаты, асыл сыйфаты итеп карала да.

Такмакларны фәнни тикшеренүләрдән бөтенләй читтә калган жанр дип әйтә алмыйбыз, галимнәребез хезмәтләрендә аларның жанрлык сыйфатларына, төп поэтик үзенчәлекләренә (Надиров И.Н., 1980), җыр классификациясендә нинди урын алып торуын ачыклауга (Миңнуллин К.М., 2003), такмакларның борынгылыгына, фольклордагы башка күп кенә күренешләр белән керешүенә (Мөхәммәтҗанова Л.Х, Миңнуллин К.М., 2021) һәм башкаларда күпмедер дәрәҗәдә игътибар бирелгән. Татарлар яши торган төрле төбәкләрдә язып алынган, халык арасында аеруча киң таралган үрнәкләр «Татар халык иҗаты» академик томнарында (Татар халык иҗаты. Йола һәм уен җырлары, 1980) урын алган.

## ХАЛКЫБЫЗНЫҢ БИЮ ТАКМАКЛАРЫ

Татар халкында популяр такмакларның асылда төп ике төрен аерып күрсәтергә мөмкин: уен такмаклары һәм бию такмаклары. Аларның бердәмлеге икесенең дә халык җырлары жанрына каравында, эстетик функцияләрендә, бию белән бәйләнгән булуларында, төп аермалары исә биюнең бер очракта, ягъни бию такмакларында тоташтан баруында, икенче очракта, ягъни әйлән-бәйлән уеннарында – уен хәрәкәтләре һәм уен вакытында әйтелә торган сүзләр белән аралашуында.

Бию такмагы белән уен такмагы арасындагы уртаклык һәм аермалар мисалларда ачык күренә. Икесенең дә биетүгә хезмәт итүләрен, тиз һәм еш кабатлана торган хәрәкәт ритмына корылуларын да бию һәм уен такмакларының уртаклыгы дип күрсәтергә мөмкин. Такмак көйләрендә милизмнар, ягъни музыкаль орнамент-бизәк юк дәрәҗәсендә. Янә килеп, аерым бию такмакларының да, уен такмаклары кебек үк, махсус көйләре бар, хәлбуки, байтагы иркен рәвештә теләсә нинди көйгә башкарыла, аларда иң мөһиме – бию хәрәкәтләренә туры килгән ритмны тоту:

*Ары баскан аягыңны*
*Бире бассаң ни була?*
*Шушы такмакларга биеп,*
*Күңел ачсаң ни була?*

Үз көе булган, яисә ярым көйләп яки төрле көйләргә кушылып әйтелә-көйләнә торган «Әпипә» такмагының да, мәсәлән төп хасияте – такмактагы иҗекләр санының бию тактына тәңгәллеге:

*Бас, кызым Әпипә,*
*Син басмасаң, мин басам;*
*Синең баскан эзләреңә*
*Мин дә китереп басам.*
*Бас, кызым, эзенә,*
*Күз тимәсен үзеңә;*
*Асыл гөлләр үсеп тора*
*Синең баскан эзеңә.*

«Әпипә»дән тыш «Әнисә», «Бие-бие, Хәйбулла», «Бие, бие, бие әле», «Бас, бас, каты бас» һәм башка такмаклар да шактый озын, буйдан буйга бию белән кушылып баралар, ягъни тоташы белән биетү тексты буларак характерланалар:

*Бие, бие, бие әле,*
*Биегәнең юк әле;*
*Биегәнең булмаса да,*
*Матур биисең әле.*
*Сикереп-сикереп биергә*
*Итек яхшы катадан;*
*Безнең болай сикерүгә*
*Фатиха бар атадан.*
*Алыйм дисәң, мал бетәрме*
*Шәһәрдәге кибеттә;*
*Биим дисәң, көй бетәрме*
*Безнең кебек егеткә.*
*Алмагачның алмасын*
*Карга-козгын алмасын;*
*Яшь вакытта биеп калыйк,*
*Үкенечкә калмасын.*
*Ай-ай, диләр, вай, диләр,*
*Бу хуҗаны бай диләр;*
*Бу хуҗаның шкафында*
*Баллы прәннек бар диләр.*
*Китайский әфлисун*
*Килә икән ящикта;*
*Картайгачтын үкенербез,*
*Биеп калыйк яшьлектә.*

## УЕН ТАКМАКЛАРЫ – ФИКЕРЛЕ СУРӘТЛӘҮ МӘЙДАНЫ

Ә уен такмагы чагыштырмача кыска була һәм әйлән-бәйлән җырларының биетү өлешен генә тәшкил итә. Менә, мәсәлән, «Кайсыгызны сайлап алыйм» уенында кара-каршы тезелгән яшьләр бер яктан икенче якка йөреп такмаклар әйтешәләр һәм аларның эчтәлегенә карап, үзләренә иптәш сайлыйлар:

*Агыйделнең аръягында*
*Үсә микән бөрлегән;*
*Кайсыгызны сайлап алыйм,*
*Барыгыз да бер дигән.*

Уен вакытында икенче якка барырга теләмәгән кеше чакыруны кире кага:

*Өстемдәге күлмәгемнең*
*Җиң очлары тар түгел;*
*Син бит матур, матурны эзлә,*
*Мин бит сиңа пар түгел.*

Әмма нәкъ менә строфалар саны шактый булганлыктан, күпчелек бию такмакларының текстларына тотрыклылык хас түгел, аларда сюжеттан сюжетка, образдан образга бәйләнеш-күперсез күчү күзәтелә.

Бию такмакларының да, уен такмакларының да төп функциясе ял итүчеләрне биетүгә, күңелләрен күтәрүгә кайтып кала. Бүгенге көндә такмакларның тормыштагы урыны нигездә бәйрәм-мәҗлесләрдә башкарыла торган уен-биюләр белән бәйле. Алардагы төп мотив биюгә өндәү-кыстау, биючегә мөрәҗәгать итү, аның хәрәкәтләрен хуплау, осталыгына соклану яисә шаяртып көлү, тексттагы шаян сүзләр аша бәйрәмдә катнашучыга әйтер сүзеңне җиткерергә омтылудан гыйбарәт («Бас, кызым, катырак», «Әнә шулай тыпырда» һәм башкалар):

*Бас, кызым, катырак,*
*Сындыр идән тактасын;*
*Сындырсаң идән тактасын,*
*Кияү түләр акчасын.*
*Бас, кызым, катырак,*
*Идәннәре селкенсен;*
*Идәннәре селкенсен дә,*
*Кияү күңеле җилкенсен.*

Уен-бию җырларының һәм такмакларының шигырь төзелеше силлабик, ягъни үзара тәңгәл тезмәләрдә иҗекләрнең бер үк санда килүенә нигезләнгән була. Чыннан да, такмакларны көйсез укып та булмый, алар ихтыярсыздан ритмга салы-

нып әйтелә башлый. Бу аларның рифмалары һәм ритмнарының бик тә төгәл булуыннан килә.

Татар халык җыр жанрында такмаклар дип билгеләнә торган төрнең тагын бер үзенчәлеге турыдан-туры аларның вазыйфасы – йола, бию хәрәкәтләренә ритм, темп биреп торулары белән бәйләнгән: йола җырларындагы кебек, аларда еш кына бернинди эчтәлеге булмаган, әмма матур, шома яңгыраган сүзләр тезмәсе билгеле бер урын ала. Бу аерым җырларның исемнәреннән үк күренеп тора: «Ал итә, итә, итә», «Айдыр-дугая», «Импаира-тиритур», «Әннәгизә-генәем, «Әлләрәйләзәйлирәйлә» һәм башкалар:

*Тәрәзә ачып җимнәр сиптем,*
*Әннәгизә-геннәгизә, геннәем,*
*Әннәгизә-геннәгизә, геннәем.*
*Ашагыз кошкайларым;*
*Әннәгизә-геннәгизә, геннәем,*
*Әннәгизә-геннәгизә, геннәем.*
*Алсу-зәңгәр чәчкә эчендә*
*Әннәгизә-геннәгизә, геннәем,*
*Әннәгизә-геннәгизә, геннәем.*
*Яшәгез, дускайларым.*
*Әннәгизә-геннәгизә, геннәем,*
*Әннәгизә-геннәгизә, геннәем.*

## БОРЫНГЫДАН БҮГЕНГӘЧӘ

Такмакның һәр сүзе биюче хәрәкәтенә, аның гамәленә бәйле. Аларда биюгә өндәү-кыстау, биючегә мөрәҗәгать итү, аның хәрәкәтен хуплау яисә шаяртып көлү нюанслары ярылып ята. Бию такмаклары, борынгы жанр буларак, әле биюләр музыка коралларыннан башка үтәлгән заманнарда ук туган һәм музыканы алмаштырып яшәгән. Такмакның үсүе ялгыз строфадан күп строфалылыкка, куплетлар арасындагы бөтенлеккә, сюжетлылыкка омтылу юнәлешендә барган дип уйларга урын бар. Хәзерге көннәргә кадәр телдә сакланган «Әпипә», «Әнисә», «Мич артында сары май», «Бие, бие, Хәйбулла» такмакларында без әнә шул бөтенлек, сюжетлылык билгеләрен күрәбез:

*Мич артында сары май,*
*Юктыр аның сызыгы;*
*Туйга килеп биемәгәч,*
*Юктыр аның кызыгы.*
*Сикереп төштем биергә,*
*Аяк астым таш кына;*
*Туйга килеп биемәгәч,*
*Нигә булдың баш кода?*
*Биек тауның башында*
*Ябалаклар азыгы;*
*Туйга килеп биемисең,*
*Әллә капка казыгы?*
*Әтәчтә дә бер исем,*
*Тавыкта да бер исем;*
*Туйга килеп биемәгәч,*
*Ник ир булып йөрисең?*
*Әй, имерә-имерә,*
*Имерә сөяк кимерә;*
*Кода кайда йөри икән?*
*Кодача идән җимерә.*
*Имән микән сайгагы?*
*Юкә микән сайгагы?*
*Имән булса бик чыдар,*
*Юкә булса шарт сынар.*
*Бас, кызым Әпипә,*
*Син басмасаң, мин басам;*
*Актык кызымның туенда*
*Басып калыйм ичмасам.*
*Бас, кызым, бас әйдә,*
*Шул «Әпипә» көенә;*
*Баса белмәгән тупашлар*
*Кайтып китсен өенә.*

Тора-бара биюләр, алар белән бергә такмаклар да музыка коралларына, бигрәк тә гармунга ияреп яши башлаган. Фольклорның «тере» үрнәге булган такмаклар, күңел ачу чарасы буларак, чагыштырмача яшәүчән жанр, аларны татарлар яши торган төрле төбәкләрдә уен һәм биюләр составында әле дә очратырга мөмкин. Куанычка, татар халкының җыр жанрын баета торган такмаклар – фольклорның бүген дә шактый актив яши торган төре. Милли йолалар һәм бәйрәмнәр, күңел ачу һәм ял итү традицияләре белән тыгыз үрелгән музыкаль-поэтик байлык, хәзерге чорда да үзенең тарихи-танып белү һәм эстетик кыйммәтен югалтмаган кадерле бер мирас, олы бер хәзинә ул татар халкының такмаклары. Уен-бию җырлары буларак характерлана торган бу төр иҗат үрнәкләре халкыбызның сурәтле фикерләү мәйданы иксез-чиксез икәнлеген, ә туган телебезнең сыгылмалы һәм шигъри бай булуын тагын бер кат исбатлый.

*Рузилә МӨХӘММӘТОВА,*
*журналист*

# Мәсгудә ШӘМСЕТДИНОВА: «Йолдыз Исәнбәт мине даһи ялкау дип сүгә иде»




***Быел Нәҗип Җиһанов исемендәге «Мирас» татар музыкасы фестивале кысаларында Мәсгудә Шәмсетдинованың «Тамгалар» симфоник әсәре яңгырады. Казан консерваториясе ректоры, фестивальнең арт-директоры Вадим Дулат-Алеев чакыруы буенча автор үзе дә Казанга кайтты. Шул форсаттан файдаланып, безнең хәбәрчебез Мәсгудә апа белән очрашты, бишек җырлары, фольклор экспедицияләре һәм Казиле авылының матурлыгы турында сөйләште.***

**Мәсгудә ШӘМСЕТДИНОВА –** күренекле татар композиторы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, философия фәннәре кандидаты. «Кыйссаи Сөембикә», «Мәһди яки изге Болгар дастаны» рок-сюитасы, «Мәхәббәтнамә», «Чыңгызхан» симфониясе, «Җир уллары трагедиясе» ораториясе һәм башкалар авторы. 2005 елда Кол Шәриф мәчете аның музыкасы белән ачылды. Башкортстанның Аскын районында туган, балачагы Казахстанның Караганда шәһәрендә узган. 2002 елдан гаиләсе белән Американың Сиэтл штатында яши. 50 яшендә машина йөртергә өйрәнә, инглиз телен үзләштерә.

## «КАЗИЛЕ АВЫЛЫНДА БИК ПОЗИТИВ КЕШЕЛӘР ЯШИ»

Мәсгудә Шәмсетдинованың ике улының берсе – Надир Баһавиев Казанда яши. Мәсгудә апа Казанга кайткан арада улы Надир Баһавиев белән килене журналист һәм шагыйрә Гөлчәчәк Шәйхетдинованың никахын уздырган. «Гөлчәчәкнең авылында никах уздырдык. Кама Тамагы районының иң матур җирендә урнашкан Казиле исемле авыл ул. Андагы кешеләр бөтенесе шулкадәр позитив, кушаматлары да матур. Минем киленнең дәү әтисе Җимеш бабай. Чәчәк апа, матур апалар бар... Безнең киленгә дә Алчәчәк дип исем бирмәкче булганнар, андый исем булмас дип, Гөлчәчәк кушканнар. Җәй көне – Гөлчәчәк, көз көне – Балчәчәк, кыш көне – Карчәчәк, яз көне Алчәчәк булыр, дигәннәр. Минем кодагый белән 10 сәгать сөйләшеп утырып була. Нинди генә сүз әйтсәң дә шигыре әзер аның. Ул аны көйләп әйтә. Бу үзе шундый шаккаткыч кешеме, әллә безнең бөтен татар халкы шундый даһимы дип уйлыйсың», – дип сөйли Мәсгудә апа.

## «БИШЕК ҖЫРЛАРЫ – МИЛЛӘТНЕҢ МӨҺЕРЕ»

Мәсгудә Шәмсетдинова Казанга кайткан арада Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында студентлар белән «Бишек көйләрендә Галәм аһәңе» исемле иҗади очрашу да уздырды. Ул гомере буе бишек көйләре җыя. «Бишек җырлары – тамга, татар милләтенең мөһере. Һәр милләтнең шундый мөһере бар. Ул халыкта күп булмый. Татарда да күп түгел: «Аллаһу-аллаһу...», «Әлли-бәлли итәр бу...», тагын өч-дүрт. Чукоткага барсаң да, Швециягә барсаң да шулай. Бишек көе – ул кешенең биометрик паспортка биргән бармак эзе кебек. Әни кеше ул кодны баланың генетикасына сеңдерә. Кешенең организмы гениаль эшләнгән, кирәк вакытта кирәк порталлары ачыла. Әйтик, «Придет серенький волчок» дип рус бишек көен тыңлап үскән баланың да берәр борынгы бабасы татар булса, ул бала татар бишек көен ишетеп, аның милли порталы ачыла. Чөнки генетикага барысы да язылган. Бишек көе «Бисмилла» кебек. Минем вазифам кая гына барсам да шуны исбат итү», – ди Мәсгудә апа Шәмсетдинова.

## КАРГАЛЫ АВЫЛЫНЫҢ 1000 ҖЫРЫ...

Композитор шатлыгын уртаклашырга ашыкты – аңа Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында лекция укыганнан соң сюрприз ясаганнар – «Татар Каргалысы җырлары / Песни Татарской Каргалы» җыентыгын бүләк иткәннәр. Китапның композитор өчен кыйммәте – анда ул үзе халыктан җыйган җырларның булуы. Мәсгудә Шәмсетдинова заманында, Казан консерваториясенең Идел буе халыклары музыка кабинетында эшләгәндә, студентлар белән бергә Оренбург өлкәсенең Каргалы авылында фольклор экспедициясендә катнашкан була. Әлеге экспедиция белән данлыклы галимә Йолдыз Исәнбәт җитәкчелек итә. Әлеге проект нәтиҗәсе 2007 елда китап булып басылып чыга. 15 елдан соң әлеге китап, ниһаять, авторына килеп ирешә.

«Шул экспедициядә 1000 җыр җыелды. 100 сәгатьлек материал тупланды. Студентларыбызның күбесе татарча белмәгәч, авыл

*«Хыялым – экспедиция материаллары Фольклор үзәге архивында яки Мирасханәдә саклансын иде. Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты фондында булса, кешеләргә кереп өйрәнү дә җиңелрәк булыр иде»*

Салават Камалетдинов,
Солтан Исхаков фоторәсемнәре

кешеләре белән миңа сөйләшергә туры килде. Экспедицияләрдә халыкны сөйләндерә белергә кирәк. Америкада индеецлар янына да барганым бар. Кая гына барсам да, тел ачкычын таба беләм. Ул күзәтә белүдән киләдер. Икенчедән, 50 елга якын шуның белән шөгыльләнәм. Шунысы сөендерә – ул вакытта экспедициядә йөргән студентларның бөтенесе фольклорчы буенча китте: Ренат Харисов хәзер Германиядә, Әлфия Һадиева Бельгиядә, Динара Булатова Петербургта яши», – дип сөйли Мәсгудә Шәмсетдинова.

Экспедициядә җыелган материал Казан дәүләт консерваториясе архивына тапшырылган. Композитор моннан бер ел элек вафат булган остазы Йолдыз Исәнбәтне сагынып искә ала, юксына. «Кайткан саен янына бара идем, – дип дәвам итә. – Ул минем композитор булып йөрүемне дә яратмый иде. «Син даһи, әмма ялкау», – дия иде миңа».

Мәсгудә ханымның җыентыкка карата кайбер ризасызлыклары да бар – ул көйләрнең кем тарафыннан язып алынуы күрсәтелмәвенә аптырый. Чөнки галимнәр этикасы буенча ул күрсәтелергә тиеш. Китапның 100 данә тираж белән генә чыгуына да борчыла. Җыентыкка җыелган җырларның бик азы гына кергәнлеген әйтә. Ул әлеге 100 сәгатьлек материалның «консерватория подвалында» гына ятмыйча, халыкка кайтарылуын тели. «Бу безнең татарлыкны саклап калу өчен бик зур ярдәм. Хыялым – экспедиция материаллары Фольклор үзәге архивында яки Мирасханәдә саклансын иде. Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты фондында булса, кешеләргә кереп өйрәнү дә җиңелрәк булыр иде», – ди ул.

«Миндә фольклор материалы бик күп, – дип дәвам итә Мәсгудә Шәмсетдинова. – Аларны ничек кенә эшкәртеп бетерермен, дим. Нәкый Исәнбәт хәреф чүпләп утыргандай, мин дә бер кешенең дә тамгасы югалмасын иде дип, көй чүпләп утырам. Аннары мин аларны http://tatarica.com/ радиома куям. Аларны төрле илләрдә яшәүче татарлар кереп тыңлый. Ләкин хәзер китап чыгарам дип уйламыйм. Минем максатым – булган материалларны интернетка урнаштыру. Интернетка урнаштыргач, аны шуннан бастырып алып, мирасханәләргә, архивларга тапшыра алам».



# МИФОЛОГИЯ – ХАЛЫК ИҖАТЫНЫҢ ИҢ БОРЫНГЫ КАТЛАМЫ

**ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫНДА ДӨНЬЯ КҮРГӘН ӘЛЕГЕ КИТАП ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫ БУЕНЧА ЭШЛӘНӘ ТОРГАН 25 ТОМЛЫК ХЕЗМӘТНЕҢ БЕРЕНЧЕ ТОМЫ. АНЫ Г. ИБРАҺИМОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ ГАЛИМНӘРЕ ӘЗЕРЛИ. ӘЛЕГЕ ЭШНЕҢ МАКСАТЫ – ХАЛЫКНЫҢ РУХИ БАЙЛЫГЫН ҮЗЕНӘ КАЙТАРУ, ПОПУЛЯРЛАШТЫРУ, КҮПЪЕЛЛЫК ФӘННИ-ТИКШЕРЕНҮ НӘТИҖӘЛӘРЕН ГОМУМИЛӘШТЕРҮ.**




*Халык авыз иҗаты буенча 12 томлык хезмәт 1976-1988 елларда бастырылган булган инде. Аңа кадәр 1965 елда – «Халык җырлары», 1946 һәм 1956 елларда – «Татар халык әкиятләре», 1951 һәм 1954 елларда «Татар халык иҗаты»ның ике томлыгы басылган.*

*Соңгы 40 ел эчендә экспедицияләрдә җыелган материалларны эшкәртеп, фәнни әйләнешкә кертеп җибәрү юлында зур эш башкарылган. Җыелган материал 25 томлык хезмәткә җитәрлек булган. Узган гасырның сиксәненче еллары белән чагыштырганда ике тапкырга күбрәк булса да, 2004 елда чуваш халык иҗатыннан 50 томлык хезмәт, башкорт халык иҗаты буенча 36 томлык чыгарырга планлаштырылуын исәпкә алганда, бу әллә ни күп түгел кебек.*

*25 томлык үз эченә «Мифология», «Йола иҗаты», «Әкиятләр», «Дастаннар», «Китаби дастаннар», «Табышмаклар», «Мәкальләр һәм әйтемнәр», «Мәзәкләр» һәм башка жанрларны ала. Быел хезмәтнең икенче томы – «Йола иҗаты» нәшер ителәчәк.*

*Инде «Мифология» чыгарылышына күчик. Мифология – халык иҗатының иң борынгы катламы. Ул иң борынгыларның дөньяны күзаллау формасы. Мифология буенча хезмәтләр һәрвакыт кызыксындыра. Мондый төр хезмәтләр арасында Сергей Бузукин нәшриятында рус телендә нәшер ителгән «Казан татарларының ышанулары» китабы да, «Смена» нәшрияты чыгарган «Мифология татар карточкалары» да, Татарстан китап нәшриятында берничә ел элек бастырылган «Татар мифологиясе балаларга» китабы да укучылар тарафыннан яратып кабул ителде. Монысы инде академик хезмәт.*

*Китапның эчтәлегенә килсәк, ул 7 бүлектән тора. Беренче бүлек «Югары аллалар. Дөнья һәм төрки кабиләләрнең яратылышы» дип атала. Бу бүлектә җирнең ничек барлыкка килүе, күкнең күтәрелүе, күктәге иң олы зат, төркиләргә башлангыч биргән бүре токымы турында текстлар урнаштырылган. Шушы ук бүлектә ташъязмаларда сакланып калган Күлтәгин һәм Тоньюкук язмалары да бирелә.*

*Икенче бүлек «Әйләнә-тирәдәге төрле объект һәм күренешләрнең килеп чыгышы» дип атала. Бу бүлектә «Иделнең акбикәне урлавы», «Иске Кама», «Яңа Казан», «Жигули казак», «Елан тавы» кебек топонимнарга бәйле риваятьләр дә, балалар фольклоры китабы аша таныш «Карлыгач койрыгы», «Чәберчек килми боз китми» кебек легендалар да бар.*

*Өченче бүлек «Беренче кешеләр һәм алып пәһлеваннар» дип исемләнгән. Бу төр мифлар төрле халыкларда бар. Бу бүлектә «Алып кешеләр», «Зур кешеләр», «Болгар пәһлеваны», «Алып тавы» һәм башка мифлар урын алган. Андый кешеләр карагай агачы кадәр озын булганнар, имеш.*

*Дүртенче бүлек «Рух-ияләр» дип аталып, күпләребезгә яхшы таныш булган ияләргә багышланган.*

*Бишенче бүлек түбән рухларга багышланган. Аларда еланнар, албасты, җен, шайтан, пәри, бичура, шүрәле, өрәк, убыр, һәм башка рухлар турында сөйләнә. Еланнарның да берничә төре: Гәрәйеш атлы елан, юха елан, утлы еланнар турында мифлар бар.*

*Алтынчы бүлек «Дәвалау һәм саклау магиясе» дип атала. Анда елан теле, пәри теле, мал корты теле, аучылар ырымы, күз тию, таң суы, зәхмәт теле, чир куу кебек әйберләр турында язылган.*

*Җиденче бүлек «Халык ышанулары» дип атала. Биредә мифологик персонажларга, табигать күренешләренә һәм халык календарена кагылышлы ышанулар, үләннәр, агачлар турындагы ышанулар, хайваннар, кошлар турындагы ышанулар, кешенең тән төзелеше һәм физик халәтенә бәйле ышанулар, тормыш-көнкүреш фактларына бәйле ышанулар, дәвалау традицияләренә кагылышлы кайбер ышанулар урын алган.*

*Әлеге томга аларның иң мөһимнәре, мәгълүмат бирү җәһәтеннән иң камилләре урнаштырылган.*

**Айсылу ГАЛИЕВА**

# ХАЙВАН ХУҖАЛАРЫ АБЗАР ИЯСЕ БАР...

Керәшен татарлары өй иясеннән башка тагын абзар иясе дә барлыгын беләләр. Абзар иясе – йорт хайваннарын, мал-туарны яклаучы, үзенә башка рух. Ул абзарда яши, абзар хуҗасы булып санала. Аның нинди рәвештә йөргәнен керәшеннәр бик төгәл белеп бетерми. Байтак бабай-әбиләрдән аның эт сурәтендә йөргәнлеген ишеткәнем бар... «Фәлән кеше абзар иясенең абзарда атларның ялларын тарап-үреп утырганын күргән», – дип сөйләүчеләр дә бар. Абзар иясен күрүчеләр әйтүенчә, атларның ялларын тарап-үреп утырганда, ул, ут кебек ялтырап, анык сурәтсез булып күренә.

Һәрвакыт абзарда яшәгәнлектән, абзар иясе күбесенчә үзенең яраткан атлары турында кайгырта, ашарына бетсә, аларга печән сала, ялларын чишмәслек итеп чуалта. Абзарда ике ат булып, аларның берсен абзар иясе яратмаса, ул төнлә гел ашамлыксыз кала. Кешеләр йоклагач, абзар иясе, аның ашамлыгын алып, үзенең яраткан атына сала. Шулай эшләп, ул яраткан атын көрәйтә, ә яратмаганын бөтенләй азапландырып, йөнтәйтеп бетерә. Шуның өстенә абзар иясе яратмаган атын, газаплап, төн буе абзарда куып йөртә, хәтта атланып та чаба. Кайвакытта иртән ат тирләгән булса, хуҗа «Атымны абзар иясе яратмый, төнлә абзарда ул атланып йөргән» дип уйлый. Шул сәбәпле, яңа ат сатып алганнан соң, керәшеннәр аны яхшы ашатып, көрәюен күзәтәләр. Әгәр дә, яхшы ашатуга да карамастан, ат яхшы көрәймәсә, керәшеннәр атны абзар иясе яратмаганлыгын аңлыйлар һәм аны тизрәк сатып җибәрү юлын эзлиләр. Атның арыклыгына башка сәбәпләр эзләп тормыйча, аны саталар...

Беркөн шулай мин күрше керәшенгә кердем. Ишегалдында яхшы гына ат йөри иде. Күршенең улы, минем иптәшем, атка карап, миңа: «Кара әле, Семён, менә бит бу атны абзар иясе бик



«Абзар иясе». 1989 ел. Әхсән Фәтхетдинов

ярата... Әнә, кара, ялларын ничек чуалтып бетергән, үзе дә шундый шома, ә без бит аны аерым туйдырмыйбыз», – диде. Мин аңа: «Нишләп инде абзар иясе аның ялларын чуалтып торсын?! Атыгыз каядыр ышкынгандыр, шуннан аның яллары чуалган...» – дидем. Иптәшем миңа яңадан: «Юк, атның яллары нигә алай үзеннән-үзе чуалсын? Атның куллары юк ич... Менә, кара, бүген мин синең алда атның ялларын сүтәм, ә иртәнгә алар тагын чуалган булырлар», – диде. Мин аңа каршы: «Бик шулай булуы бар! Сез бит атыгызның ялларын бервакытта да яхшылап юып-чистартып тарамыйсыз, атыгыз ышкына да аның яллары искечә чуала», – дидем. Мин уйдырмаларга каршы тагын күп сүзләр әйттем, ләкин ул миңа ышанмады, үз уенда, атның ялларын абзар иясе чуалта дигән ышануында калды.

Керәшеннәр уйлавынча, абзар иясе дә, өй иясе кебек, аны онытмаган хуҗаның мал-туарына зыян китерми. Әгәр дә йорт хуҗасы абзар иясенә хөрмәт күрсәтергә оныта икән, ул хайваннарга төрле зыян китерә: үләт җибәрә, кысыр калдыра һ.б. Абзар иясенең ачуын китермәс өчен, керәшеннәр ел саен «абзар урынын уздыру» корманын (корбан йоласы) оештыралар.

Бу корман алдан ук тамгалап куелган берьеллык бәрән чалудан тора. Гадәттә, һәр хуҗа абзар иясенә корманга беришле төстәге бәрәнне чала, мәсәлән, караны. Шуннан соң инде хуҗа ел саен кара бәрән чалырга тиеш була – башка төстәге корман бәрәнен абзар иясе кабул итми. Әгәр дә хуҗаның бирәр елда кара бәрәннәре булмый икән, ул елны корман китерелми, каралар туган елга калдырыла.

Абзар иясе хөрмәтенә корман чалуның керәшеннәрдә төгәл билгеләнгән көне юк. Гадәттә, ул көз көне, кыр эшләре беткәч, түбәндәгечә башкарыла: кояш баеп, караңгы төшкәч, тамгалап куелган бәрәнне абзарга кертеп, дүрт аягын бергә бәйлиләр дә чалалар. Чалучы йортта иң олы ир кеше булырга, һәм ул башына бүрек киярга тиеш.

Чалынган малның эчке әгъзаларын шунда ук абзарда күмәләр, итен пешерергә өйгә алып керәләр. Йорттагы иң олы хатын-кыз бу итне төн уртасы җиткәнче пешереп өлгертергә тырыша. Төн урталары җиткәч, пешкән ит казаннан табакка салына. Йорт хуҗасы белән хатыны табакны кулларына тотып, абзарга чыгалар да билгеләнгән җирдә абзар иясенә, мал-туарлар файдасына дип, келәү әйтәләр. Келәүдән соң йорт хуҗалары корман итен күтәреп өйгә керәләр, барысы да өстәл артына утырып корман итен ашый. Бу итне шул ук төнне ашап бетерү тиеш. Корман бирүче йорт хуҗасының гаиләсе аз булса, ул вакытта, чалынган бәрәнне пешерергә салганчы, буйга – башыннан койрыккача урталай кисеп казанга салалар, икенче яртысын калдыралар. Керәшеннәр уйлавынча, бәрәннең пешерелгән яртысы бөтен бәрәнне алмаштыра. Бәрәннән калган сөякләрне хуҗалар, корман ашыннан соң, шунда ук абзарга алып чыгып, чалынган бәрәннең эчке әгъзалары янына күмәләр.

Абзар иясенә корман багышланган көнне керәшеннәр өйләренә чит кешене кертмиләр, ишегалдына да уздырмыйлар. Бу көнне килгән кунакларга алар: «Бүген без сине каршы ала алмыйбыз, иртәгә килерсең», – диләр. Килгән кунак борылып китә.

# «Карга боткасы» йоласы





*Татарларның традицион бәйрәм культурасының үзенчәлеге үз эченә дини һәм дөньяви бәйрәмнәрне алуда. Дөньяви бәйрәмнәрнең катгый итеп билгеләп куйган датасы юк, үткәрү вакытын елның климат шартларына һәм һава торышына карап аксакаллар билгели. Мондый бәйрәмнәрнең хуҗалык эшчәнлеге этапларына бәйлелеге дә күзәтелә.*





Шундый бәйрәмнәрнең берсе – «Зәрә боткасы» («Карга боткасы») йоласы. Әлеге бәйрәмнең тирән тамырларына күз салсак, кара карга культына барып тоташа. Татар халкы ышанулары буенча, кара каргалар канатларында яз китерә, ягъни, алар кыш белән язның арадашчысы ролендә карала. Чөнки каргалар күчмә кошлар арасында иң соңгы китүчеләр һәм тәүге очып килүчеләр – янәсе, җирнең җанын алып китәләр дә, иң алдан китереп тә куялар.

Әлеге йола халыкта төрле исем белән атап йөртелә, мәсәлән, Казаннан төньяк-көнчыгыш районнарда – *«дәрә боткасы, зәрә боткасы»*, Татарстанның көнчыгыш районнарында һәм Башкортстанның төньяк-көнбатышында – *«карга боткасы»*.

Йоланың төп эчтәлеге түбәндәгечә: иртә язның беренче көннәрендә, ала каргалар күренә башлагач, балалар йорт саен йөреп ярма, сөт, май, йомырка җыя. Йортларга кергәндә әйтелә торган билгеле бер ырымлы сүзләр дә була.

Кирәкле ризыклар җыелгач, балалар ачык кырга юнәлә. Берничә өлкән хатын-кыз булышлыгында җыелган әйберләрдән ботка пешереп, бөтен авыл халкы сыйлана. Һәр кеше үз тәлинкәсе-кашыгы белән килә. Бәйрәм уеннар белән дәвам итә.







Хәзерге вакытта «Карга боткасы» Кукмара районының Кенәбаш авылында элеккеге хәлендә сакланып калган һәм уткәрелеп килә.

Йоланың май бәйрәмнәренә туры китерелеп уткәрелүе авыл халкына гына түгел, шәһәрләрдә һәм башка авылларда яшәүчеләргә дә, укырга киткән студентларга да кайтып, матур бәйрәмдә катнашу мөмкинлеге бирә.



**ЙОЛА ӨЧ ЭТАПТАН ТОРА:**

– ризык җыю;
– ритуаль ботка пешерү;
– халык уеннары.

Этаплар берничә элементка бүленгән:

**1** Иртә таңнан малайлар йорт саен кереп ботка пешерү өчен ризык җыя. Коры ингредиентлар капчыкка салына, май белән сөт – аерым чиләкләргә. Малайларга ризык чыгарып биргән авыл карчыклары: *«Елларга тынычлык бир!»* – дип дога кыла.

Балалар бер генә йортны да читләтеп үтми, авылның һәр кешесе йолага үз өлешен кертергә тырыша.

**2** Ботканы тәҗрибәле хатын-кыз пешерә. Аның су китерергә, ярма юарга ярдәмчесе дә була. Әлеге булышучы пешекчедән ботка пешерү серләрен дә өйрәнә. Ботка ике-өч зур казанда пешерелә.

**3** Халык уеннары. Алар шушы җирлек өчен хас уеннар була.

«Карга боткасы» йоласының структур элементы – йомырка. Ботка ашагач балалар таудан йомырка тәгәрәтеп уйный. Берләре өстән тәгәрәтеп җибәрә, икенчеләре астан тотып ала. Бу уен яңа гына кышкы йокыдан уянган җирне аталандыруны гәүдәләндерә. Йола мәдәният йорты хезмәткәрләре оештырган башка заманча уеннар белән дә тулыландырыла.

Әлеге йола үткәрелгәндә вакыт кысалары һәм төп этаплар сакланса да, төрле төбәкләрдә җирле традицияләр кертелүен күрәбез: мәсәлән, буялган йомыркалар җыела, ритуаль ботка пешкәндә чәй табыны оештырыла, уеннар өстәлә.

«Карга боткасы» – тәрбияви рольне үтәүче матур йола. Әлеге йоланың социомәдәни тирәлеккә керүе традицияләрне яңартып кына калмый, авылдашларны берләштерә һәм традицияләрнең буыннан буынга күчешен күрсәтә.

**«Татарстанның мәдәният ресурс үзәге» сайтыннан**

Гөлназ Латыйпова фоторәсемнәре

# Авылда

Нурзия Мирхазова сүзләре,
Наилә Яхина көе




Тау битендә җиләк пешкән
Әллә мине көткәнме?
Гади генә түгел болын,
Гүя чәчәк түтәле.

**Кушымта:**
*Чәчәкле болыннары,*
*Болында колыннары!*
*Суга тиеп тора таллар –*
*Сүтелгән толымнары.*

Шуңа ел да сагынып кайтам
Әткәм үскән җирләргә.
Әни кулының җылысы
Бардыр җәйге җилләрдә.

**Кушымта.**

*Рәзинә САЙФЕТДИНОВА,*
*Питрәч, Кибәк Иле авылы*
*мәдәният йорты директоры*

# «Түбәтәй» уены

(МИЛЛИ УЕННАР ҖЫЕЛМАСЫННАН)



***Элек-электән авылда булсынмы, каладамы – һәр татар өендә түбәтәй булган. Чәчләре кырдырып алынган мөселман егетенең баш түбәсенә бәрхет яисә вельвет түбәтәй менеп «кунаклаган». Хәтта бүрек, эшләпәише баш киемнәре кигән чакта да түбәтәй салынмаган, эчке баш киеме булып калган. Авылдагы татар апалары яулык өстеннән ирләр түбәтәе кигән. Казан артында түбәтәйне «кәләпүш» һәм «такыя» дип йөрткәннәр. Заманына күрә алар формасы, тегелү рәвеше белән генә аерылып торган.***

Такыя – гадәти бәйләнгән башлыкларга охшатып, ярым форма рәвешендә дүрт өлгедән тегелә. Аның килеп чыгышы турында төрле фикерләр бар. Берәүләр аны урта гасыр сугышчысының очлым (шлем) астыннан киелгән баш киеменнән килеп чыккан дип саный. «Түбәтәй» сүзе үзе дә «түбә», ягъни баш түбәсенә киелүче әйбер мәгънәсен аңлатып тора. «Такыя» исә чәчәкләрдән үрелгән таҗ буларак билгеле. Кәләш бирнәсенә дә күлмәк, аякчу кебек әйберләр белән бергә, такыя да кергән. Яшь кешене никахы белән котлаганда: «Такыяң котлы булсын!» дигәннәр. Такыя – ирләр түбәтәе генә түгел, кызларның баш киеме дә. Аны 8-12 яшьлек кызлар киеп йөргән. Җиткән кызлар, кияүгә чыгучылар түбәтәйне калфакка алыштырганнар. Димәк, баш киемен алыштыру әле ул яшь үзенчәлеген дә, кешенең җәмгыятьтәге урынын да билгеләгән. Тугандаш төрки халыкларның культурасына күз салсак, аларда да яшь кызларның такыя кигәнен күрәбез. Мәсәлән, төрекмән кызлары шундый такыяларын махсус очлым – көмеш көпбә белән бизәгәннәр. Аның көпшәсенә ябалак каурыйлары утыртып куйганнар. Каурый булмаса, ул инде ярәшелгән кыз дигән сүз. Түбәтәйнең көпбәдән түбән өлешенә көмеш тәңкәләр тезгәннәр.

Түбәтәйнең икенче төре – кәләпүш – кулланылышка соңрак, XIX гасырның 60 нчы елларында гына килеп керә. Аның формасы да такыядан үзгәрәк: яссы түгәрәк түбәле һәм каты кырыйлы. Кәләпүш борынгырак заманда киелмәгәнгә күрә, галимнәр аны төрекләр кия торган фәстән килеп чыкмадымы икән, дип уйлый. «Кәләпүш» сүзе исә таҗик теленнән алынган: «кәллә» – баш, «пушидан» – каплау, кию мәгънәсендә. XIX гасыр ахырында кәләпүшләр түбәтәйләрне кысрыклап чыгара һәм татарларның төп баш киеменә әверелә. Татар эшмәкәрләре һәм зыялылары аны аеруча яратып кия. XX гасыр башында төшерелгән фоторәсемнәрдә без еш кына зыялы-затлы татар ирләрен кара казакин һәм гади кара кәләпүштән күрәбез. Бу баш киеме бүгенге көндә дә яшәп килә. Кәләпүш җитештереп сатучылар аларга үз яңалыкларын, өстәмә бизәкләрен куша.

Шушы матур баш киеменә, татар халкы «Түбәтәй» исемле уен да уйлап тапкан. Әйдәгез бергәләп уйныйбыз.



Автор фоторәсеме

**УЕН ТӘРТИБЕ:**

1 Уенчылар түгәрәккә баса. Жырлый-жырлый, түбәтәйне бер-берсенә бирәләр.

*Түбәтәйне кигәнсез,*
*Бик ераклардан килгәнсез,*
*Төскә матурлыгы белән*
*Шаккаттырыйм, дигәнсез.*

***Кушымта:***
*Туп-туп-түбәтәй,*
*Түбәтәең укалы.*
*Чиккән матур түбәтәең*
*Менә кемдә тукталды.*

2 Жыр ахырында түбәтәй кемдә калса, шуңа жәза бирелә (уенчы бии, жырлый, әтәч булып кычкыра). Уен шулай дәвам итә.

«Түбәтәй» уенында балалар бер-берсенә ярдәм итәргә өйрәнә. Уен балага кыюсызлыкны жиңәргә булыша, чөнки кайбер бала башкалар алдында нинди дә булса хәрәкәт башкарырга уңайсызлана, уенда исә ул иптәшләренә кушылып эшли.

***Каян килеп чыккан соң бу уен? Кибәк Иле авылында яшәүче 86 яшьлек Люция әби САФИНА «Түбәтәй» уены турында менә нинди сөйләде:***

*– «Түбәтәй» уены рус халык уены «Колечка»-га бик охшаган. Анда уенчылар йөзек куллана, ә безнең уенда түбәтәйне кулдан кулга йөртәләр. Чөнки элек татар малайлары өйдә дә, урамда да түбәтәйдән йөри иделәр. Шуңа аны кулдан кулга тапшырып, уен уйнарга да уңайлы иде. Бу уенның каян килеп чыгышы турында бездә болай сөйлиләр иде. Бервакыт татар авылына кунакка Үзбәкстаннан Назыйм исемле малай кайта. Аның тамырлары Нурлат авылыннан була. Туганнан туган Нурулла абыйсы, авыл малайлары белән таныштыру өчен, Назыймны урамга алып чыга. Ялтыр-йолтыр килеп торган вак ташлар белән бизәлгән түбәтәй кигән Назыймны күреп авыл малайлары шакката, аның түбәтәенә кызыгалар, тотып карыйсылары килә. Шул чакта Нурулла абыйсы: «Әйдәгез, барыгыз да түгәрәккә басыгыз һәм түбәтәйне бер-берегезгә тапшырыгыз, ә мин гармунда уйнармын. Гармун туктаганда түбәтәй кемдә кала – шуңа жәза бирербез, кемдер жырлар, кемдер биер», – ди. Әлбәттә, малайлар шатланып ризалашалар, уенга керешәләр. Шуннан бирле уен «Түбәтәй» дип атала».*

# Гөбәдия

УЗГАН ЕЛНЫҢ ДЕКАБРЕНДӘ БАШЛАНЫП КИТКӘН «ТАТАРХАНӘ» ПРОЕКТЫНЫҢ «ТАТАР ТАБЫНЫ» РУБРИКАСЫН ДӘВАМ ИТӘБЕЗ. «ТӘМЛЕ БУЛСЫН» РЕСТОРАННАР ЧЕЛТӘРЕ ҖИТӘКЧЕСЕ, ТАТАР АШЛАРЫ ҺӘМ МӘДӘНИЯТЕ ХАЛЫКАРА АССОЦИАЦИЯСЕ ПРЕЗИДЕНТЫ, ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ АТКАЗАНГАН ХАЛЫККА ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮ ӨЛКӘСЕ ХЕЗМӘТКӘРЕ, ТАНЫЛГАН АШ-СУ ОСТАСЫ **РЕЗИДӘ ХӨСӘЕНОВА** БЕЛӘН ТАТАРСТАННЫҢ АТКАЗАНГАН АРТИСТЫ **ДИНӘ ЛАТЫЙПОВА** БҮГЕН СЕЗНЕ ГӨБӘДИЯ ПЕШЕРҮ СЕРЛӘРЕНӘ ӨЙРӘТӘЛӘР.



Гөбәдия – татар милли камыр ризыгы, ул әче камырдан күпкатлы итеп ясалган пирог. Татар телендә «гөбәдия» сүзенең «гөлбәдийә» (Пермь сөйләме), «гөлбәдия» (Нократ сөйләме) вариантлары очрый.

Бүгенге көндә гөбәдия табынга десерт итеп бирелә. Аның эченә бөрттерелгән дөге, йөзем җимеше, пешкән йомырка, кара җимеш, өрек һәм гөбәдиягә үзенчәлекле тәм бирүче төп ингредиент – корт салалар. Этнограф, галим К. Насыйри бу милли ризык турында болай дип яза: «Әмма гөбәдия дигәне һәм бәлеш кебек түгәрәк буладыр. Ләкин гөбәдиягә итне турап салмыйлар, чабып салалар бик вак итеп аска, аның өстенә корт салалар, аның өстенә йомырканы пешереп, төеп салалар, май салалар. Бәлеш кебек итеп камыр белән төрәләр; зиядә хуп нигъмәт була» . Корт эремчектән ясала. Эремчеккә атланмай, шикәр комы салына һәм суы беткәнче сүрән генә утта кайнатыла. Кортны бал, атланмай кушып болай да кулланырга мөмкин. Сүрән генә утта кайнатылган корт йомшак була, ә шикәр комы аңа төс бирә. Кайнатылган кортның төсе алтынсудан алып кызыл төскә кадәр булырга мөмкин (шикәр комын күбрәк кушсаң, ул кызыл төскә керә).

Элек-электән гөбәдия аш-су мәҗлесләрендә төп сыйларның берсе булган. Гадәттә, аны туйга кәләш үзе әзерләгән. Кайбер якларда туйга бу камыр ризыгын кияү алып килгән. Әгәр дә буйга



житкән кыз оста итеп гөбәдия пешерсә, аны инде кияүгә бирергә вакыт дип санаганнар. Уңган кызлар пешергән гөбәдиянең эче һәрвакыт чәчелеп торган, ә төбе (уртасы) коры булып пешкән. Мулла никах укып, яңа туган гаиләне котлагач, табынга чыгарылган.

Гөбәдия кисүнең үз йоласы булган: аны сак кына, уртасы күренеп торырлык итеп кисқәннәр. Кияүнең әтисе гөбәдиянең беренче кисәген алып, аңа тәңкә (акча) салган – бу гөбәдия сатып алу күренеше. Аның катламнары һәрвакыт так итеп ясалган, гадәттә, гөбәдиядә ничә катлам булса, кияү шулкадәр кәләш йортында кала алган.

Гөбәдияне чәй белән дә, десерт итеп тә бирергә, әгәр дә ул ит белән пешерелсә, төшке, кичке ашны да алыштырырга мөмкин. Гөбәдияне табынга кечкенә тәлинкәләргә салып, янына балкашык куеп чыгаралар.

Гөбәдия әзерләүнең ысуллары күп. Һәркем үзенә ошаган вариантны сайлап ала. Гасырлар дәвамында аның төп ингредиентлары үзгәрмәгән диярлек, тик кайберләре үзләренә тиңдәш продуктларга алыштырылган.

## КИРӘКЛЕ ИНГРЕДИЕНТЛАР:

**Камыр өчен:**

400 г он,
2 йомырка,
250 мл сөт,
20 г чүпрә,
150 г көнбагыш мае,
100 г атланмай,
2 балкашыгы шикәр комы,
төменчә тоз.

**Эчлек өчен:**

300 г бүрттерелгән дөге,
200 г йөзем җимеше,
5 йомырка,
300 г корт,
250-300 г атланмай,
2 аш кашыгы шикәр комы,
5-6 данә күрәгә, кара җимеш.



1

Алда әйтелгән барлык ингредиентларны кушып, йомшак кына камыр басабыз. Камырны ясагач, 10 минутлап ял иттерәбез



2

Камыр ял иткән арада гөбәдия эчлеге әзерлибез: әзер кортны суыткычтан алабыз, дөгене бүрттерәбез, йөземне, күрәгәне, җимешне юып киптерәбез, йомырканы пешереп, эре угычта уабыз, атланмайны эретәбез



3

Камырны икегә бүлеп, зуррак өлешен нәзек итеп җәябез



**4**

Килеп чыккан түгәрәк җәймәне таба өстенә куеп, тигезлибез



**5**

Табадагы җәймә өстенә әзерләп куелган эчлекне – корт, дөге, йөзем, йомырка, җимешне катлам-катлам итеп җәябез, шикәр комы сибәбез, атланмай салабыз



**6**

Калган камырдан җәймә ясап, каплап куябыз. Өстен камырдан ясалган чәчәкләр белән бизибез. Атланмайны шикәр комы, он белән уып сибеп, кайнар мичкә куеп, 180 градуста 30-35 минут пешерәбез

***Ашларыгыз тәмле булсын!***

Фоторәсемнәр Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге архивыннан

# Шахворд

Хөрмәтле укучылар! Таблицадагы хәрефләр тезмәсеннән шахмат фигурасы – ферзьнең дөрес йөреш тәртибен кулланып, шагыйрь Роберт Миңнуллинның «Сабантуй бүген бездә!» шигыренең бер куплетын укыгыз.

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Җ | е | р | н | с | к | л | ә |
| и | ф | д | ә | ө | ә | ә | р | ш |
| л | и | к | л | л | р | ө | и | - |
| ч | к | г | ү | - | К | к | а | С |
| и | е | Б | к | ә ! | т | т | а | г |
| л | р, | ү | г | ә, | к | б | ү | е |
| ә | б | з | у | й | а | б | н | ә! |
| е | е | з | ы | н | й | б | д | |
| б | ы | ш | т | у | е | з | | |

Шахвордның җавабы – саннарда
Бер сан бер хәрефкә туры килә. Шигъри юллар 77 хәрефтән тора.

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 1 | 5 | 6 | 14 | 15 | 27 | 28 | 44 |
| 2 | 4 | 7 | 13 | 16 | 26 | 29 | 43 | 45 |
| 3 | 8 | 12 | 17 | 25 | 30 | 42 | 46 | 59 |
| 9 | 11 | 18 | 24 | 30 | 41 | 47 | 58 | 60 |
| 10 | 19 | 23 | 32 | 40 | 48 | 57 | 61 | 70 |
| 20 | 22 | 33 | 39 | 49 | 56 | 62 | 69 | 71 |
| 21 | 34 | 38 | 50 | 55 | 63 | 68 | 72 | 77 |
| 35 | 37 | 51 | 54 | 64 | 67 | 73 | 76 | |
| 36 | 52 | 53 | 65 | 66 | 74 | 75 | | |



Ферзьнең дөрес йөреш тәртибе.

**Шахвордның җавабы:**

Җилфәрди чиккән сөлгеләр,
Бүләкләр – күбәбезгә!
Керешик тә, узышыйк та –
Сабантуй бүген бездә!

**Педагогия фәннәре кандидаты, Халыкара педагогик белем фәннәре академиясе академигы Нәҗип ШАКИРҖАНОВ төзеде**

# Истәлекле даталар
2022

## ИЮЛЬ

**1 июль**

График Гөлзирә Солтан кызы Бекташевага 75 яшь (1947)

**2 июль**

Тел галиме, филология фәннәре докторы, профессор, Татарстан ССРның һәм Россия Федерациясенең атказанган фән эшлеклесе, Татарстан Республикасының фән һәм техника өлкәсендә Дәүләт премиясе лауреаты Гомәр Фәез улы Саттаровның тууына 90 ел (1932-2020)

**4 июль**

Гамәли бизәлеш сәнгате рәссамы Татьяна Васильевна Макаровага 70 яшь (1952)

**12 июль**

Татарстан Республикасының халык рәссамы, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре Александр Федорович Иншаковка 75 яшь (1947)

**16 июль**

Баянчы, Татарстанның халык артисты Рамил Сөләйман улы Курамшинга 75 яшь (1947)

**20 июль**

Балалар язучысы, А. Алиш исемендәге әдәби бүләк иясе Алмаз Марс улы Гыймадиевка 50 яшь (1972)

**22 июль**

Гамәли бизәлеш сәнгате рәссамы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Мария Семёновна Килдебәкованың тууына 90 ел (1932-2017)

## АВГУСТ

**1 август**

Татарстан Республикасының халык рәссамы, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Шамил Мортаза улы Шәйдуллинның тууына 75 ел (1947-2021)

**15 август**

Театр рәссамы һәм график, ТАССРның халык, РСФСРның атказанган рәссамы, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Эрнст Брунович Гельмсның тууына 110 ел (1912-1992)

**16 август**

Шагыйрь Рамил Мотаһар улы Чурагуловка 60 яшь (1962)

**19 август**

Рәссам, реставратор, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Айдар Нурмөхәммәт улы Хисамовның тууына 60 ел (1962-2019)

**19 август**

Рәссам Нияз Нурмөхәммәт улы Хисамовка 60 яшь (1962)

**20 август**

Режиссёр, педагог, ТАССРның һәм РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе Илгиз Габидулла улы Мәҗитовның тууына 90 ел (1932-2004)

**21 август**

Актриса, Татарстанның халык артисты Ләлә Рафаил кызы Миңнуллинага 70 яшь (1952)

## СЕНТЯБРЬ

**7 сентябрь**

Сәнгать белгече, сәнгать фәннәре кандидаты Фирдәүс Гомәр кызы Ваһаповага 60 яшь (1962)

**18 сентябрь**

Җырчы, конферансье, режиссёр, язучы-сатирик, җырлар авторы, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Алмаз Наил улы Хәмзинга 75 яшь (1947)

**19 сентябрь**

Шагыйрь, тәрҗемәче, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Нури Газиз улы Арслановның тууына 110 ел (1912-1991)

**20 сентябрь**

Актёр, режиссёр, ТАССРның халык, РСФСРның атказанган артисты Камил Шакир улы Вәлиевкә 80 яшь (1942)

**29 сентябрь**

Актриса, ТАССРның халык, РСФСРның атказанган артисты Гәүһәр Габдулла кызы Камалованың тууына 100 ел (1922-1990)

**https://kitaphane.tatarstan.ru сайтыннан алынды**







**Кадерле укучыларыбыз!**
2022 елның икенче яртыеллыгы өчен «Түгәрәк уен» альманахына республикабызның барлык элемтә бүлекләрендә, яисә «Почта России» сайты аша (https://podpiska.pochta.ru Индекс ПА 183 яисә «Тугарак уен» дип җыярга) онлайн да язылырга мөмкин.

**Индексыбыз – ПА 183**
**Өч айга язылу бәясе – 283 сум 39 тиен**
**Ярты елга язылу бәясе – 566 сум 78 тиен**

БЕРГӘ БУЛЫЙК, ДУСЛАР!